ИСЛАМСКАЯ БИБЛИОТЕКА

# КӨЙЛӘП УКЫРГА ӨЙРӘНӘБЕЗ

## ТАТАР РУХИ МИРАСЫ ӘСӘРЛӘРЕН БАШКАРУЧЫЛАРГА МЕТОДИК ӘСБАБ

КАЗАН 2022

УДК 398.88

серия «Исламская библиотека»

Көйләп укырга өйрәнәбез. Татар рухи мирасы әсәрләрен башкаручыларга методик әсбаб / төз. Л.Х.Җиһаншина, Р.Р.Сафиуллина, Л.И.Сәрвәрова. – Казан: Россия ислам институты, 2022. – 97 б.

Методик әсбап үз эченә татар лиро-эпик традициясенә караган материалларны (шигъри текстлар, көйләр, аналитик мәкаләләр) ала. Әлеге басма укытучыларга, фольклор ансамбльләре җитәкчеләренә, шулай ук барлык татар халкының рухи мәдәнияте белән кызыксынучыларга файдалы булачак.

© Россия ислам институты
© Казан дәүләт консерваториясе
© Җиһаншина Л.Х.
© Сафиуллина Р.Р.
© Сәрвәрова Л.И.

# ЭЧТӘЛЕК

МОҢ ИЛЕНӘ СӘЯХӘТ . . . . . 5
ИСЛАМ ҺӘМ МУЗЫКА. МӘГЪРИФӘТЧЕЛӘРЕБЕЗ КӨЙ-МОҢ ТУРЫНДА, ЯГЪНИ КӨЙ КӨЙЛӘҮ ХӘЛӘЛМЕ? . . . . . 8
КӨЙЛӘП УКУ СӘНГАТЕ. . . . . 15
ТАТАРНЫҢ ИСКЕ КЛАССИК МУЗЫКА СӘНГАТЕ ЖАНРЛАРЫ . . . . . 24
Бәет . . . . . 26
Робагый (әрбагый, ырбагый) . . . . . 28
Касыйдә . . . . . 29
Газәл. . . . . . 30
Иляһи . . . . . 30
Зекер (зикер, әзкар) . . . . . 31
Хушаваз . . . . . 32
ИЛЯҺИ БӘЕТЛӘР ҺӘМ УЕН КОРАЛЛАРЫНДА УЙНАУ . . . . . 34
РУХИ МИРАСЫБЫЗ ЯДКАРЬЛӘРЕ . . . . . 44
КОЛ ШӘРИФ . . . . . 44
МӨХӘММӘДЬЯР . . . . . 48
Игелекле булсын кеше . . . . . 48
Нәсыйхәт . . . . . 49
СУФИ АЛЛАҺИЯР . . . . . 50
Гамәлдә Аллаһыга табыну. . . . . . 50
Акыллы эшкә боеру хикәяте . . . . . 51
МӘҮЛА КОЛЫЙ . . . . . 52
Хикмәтләр . . . . . 52
ГАБДЕРӘХИМ УТЫЗ ИМӘНИ . . . . . 55
Синең биш асылың . . . . . 55
ЯХЪЯ БИНЕ СӘФӘРГАЛИ (ЯХЪЯ ИШАН) . . . . . 57
Васыятьнамә . . . . . 57

МӨНӘҖӘТЛӘР . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 59
ЙӘ РӘСҮЛЕМ МӨХӘММӘТ! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 59
ДИДЕ МУСА . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 61
ӘЛВИДАГ! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 62
ӘЛВИДАГ! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 64
МӘРХАБӘ . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 66
ЛӘ ИЛӘҺӘ ИЛЛӘЛЛАҺУ . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 67
КОРБАН МӨНӘҖӘТЕ . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 69
МӘҮЛИД . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 70
ӘМИНӘ ХАНЫМ – МӨХӘММӘТ АНАСЫ . . . . . . . . . 72
МӘҖЛЕС МӨНӘҖӘТЕ . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 75
МӘҖЛЕС МӨБАРӘК БУЛСЫН . . . . . . . . . . . . . . . . 76
САБЫРЛЫК МӨНӘҖӘТЕ . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 77
ВӘЙС ӘЛ-КАРАНИ. . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 78
ДӘРВИШЛӘРНЕҢ СӨХБӘТЕНДӘ. . . . . . . . . . . . . . . 80
МӘРХАБӘ! . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 81
ХЫЗЫР ИЛЬЯС . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 82
КЫЙССАИ ЙОСЫФ . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 83
МӨХӘММӘДИЯ . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 84
БӘДӘВАМ . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 85
АХЫРЗАМАН яки ТӘКЫЙ ГАҖӘП. . . . . . . . . . . . . . . . 86
МАНАРА БӘЕТЕ . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 88
АУДИОЯЗМАЛАРГА КОММЕНТАРИЙЛАР . . . . . . . . . . 90
РУХИ МИРАС ӘСӘРЛӘРЕН БАШКАРУЧЫЛАР БӘЙГЕ-ФЕСТИВАЛЕ «ИЛАҺИ МОҢ» КЫСАЛАРЫНДА УЗДЫРЫЛГАН «ТАТАР РУХИ МИРАСЫНДА ГЫЙБАДӘТ ҺӘМ МУЗЫКА» ТҮГӘРӘК ӨСТӘЛ РЕЗОЛЮЦИЯСЕ . . . . . . . 92

# МОҢ ИЛЕНӘ СӘЯХӘТ

Иң мөкаддәс өч нәрсә бар - тел, моң, хәтер. Шул өч мәңгелек кыйммәт, дин яктысы белән сугарылып, рухны савыктыра. Ә рухы сау милләт яши, аның киләчәге бар. Татар халык авыз иҗаты әсәрләренең тел, моң, хәтер сагында торуы, дини кыйммәтләр белән бәйле булуы, Мәхмүд Кашгарыйның “Диване лөгать әт-төрк” (“Төрки телләр сүзлеге”) китабында чагылыш табып, Ибн Фадлан, Әл-Гарнати һәм башка галим-сәяхәтчеләрнең әсәрләрендә дә искә алына.

Кол Гали, Хәрәзми, Мәхмүд Болгари, Котб, Сәйф Сараи, Мөхәммәдьяр, Мөхәммәд Әмин, Кол Шәриф, Мәүлә Колый, Утыз Имәни, Акмулла һәм башка затлы шагыйрьләребезнең иҗаты, аһәңе, гасырларны кичеп, бүгенге көнгә кадәр сакланып килеп җиткәннәр.

Халык иҗаты дәрьясының мәкальләр һәм әйтемнәр, риваятьләр һәм легендалар, мәзәкләр, табышмаклар, мәкаль-әйтемнәр, дастаннар һәм җырлар кебек берсеннән-берсе тирән һәм саекмас чишмәләре арасында мөнәҗәт-бәетләр аерым бер куәтле вә күркәм тармакларны тәшкил итә.

Мөнәҗәтләр – әдәбият белән фольклор арасында торган лирик жанр. Алар язма поэзия белән халык иҗаты традицияләре үзара очрашкан һәм бергә үрелгән ноктада барлыкка килгәннәр, һәм элек-электән үк шушы ике башлангычка таянып иҗат ителгәннәр. Мөнәҗәтләрнең эчтәлеге дә еш кына ике төрле катламның, ягъни дини һәм дөньяви башлангычның үзара үрелүенә корыла.

Дини мөнәҗәтләрдә авыр хәлдә калган яисә үлем заруриятын тойган герой Аллаһка мөрәҗәгать итә, аннан сабырлык, түземлелек бирүен сорый яки гөнаһларын ярлыкавын үтенә, тәүбә итә. Мондый әсәрләрдә дини мотивлар халыкның үлем һәм яшәү мәгънәсе турында фәлсәфи уйланулары белән керешеп китә, кеше бу дөньяда кунак кына, беркем дә мәңгелеккә килми. Димәк, инсан үз гомерен бушка-әрәмгә түгел, ә максатчан һәм матур итеп уздырырга тиеш. Нинди генә авыр хәлләрдә дә кеше кеше булып кала белсен. Мөнәҗәтләрдә әнә шундый тирән фәлсәфи фикерләр ярылып ята. Шул ук вакытта аларда халыкның гасырлар буена формалашкан мораль-әхлак нормалары да гәүдәләнә: кешене рәнҗетмә, хәрам мал җыйма, ятимнәр өлешенә кермә, үзеңнән олыга-кечегә шәфкатьле бул, ата-анаңны хөрмәтлә һәм тәрбия ит.

Күп мөнәҗәтләрнең үзәгендә аерылу мотивы ята: герой, ниндидер сәбәп белән, туган иленнән, җиреннән, ата-анасыннан, якыннарыннан аерылган, я булмаса, ул якты дөньядан китү алдында тора. Мондый әсәрләрдә инде аерылуга бәйле хисләр, моң-зар, кайгы-сагыш тойгылары алгы планга чыга. Мөнәҗәтләрне, башлыча, гыйлемле, укый-яза белгән кешеләр иҗат иткән. Күбесе, төрле кульъязма җыентыкларда, дәфтәрләрдә тупланып, бу көнгәчә килеп җиткәннәр. Халык аларның һәркайсын кабатланмас көй, моң белән башкарган.

Мөнәҗәтләр - кешенең шәхси-психологик кичерешләре турында сөйләүче, аларны чагылдыручы һәм эчке дөньясының иң тирән серләрен гәүдәләндерүче жанр. Бәетләр исә, нигездә, аерым кешенең генә түгел, ил һәм халык язмышының да фаҗигале якларына кагылалар. Башка халыкларда безнең бәетләргә тәңгәл әсәрләр юк. Бәетләрдә аерым шәхесләрнең тормышында булган фаҗигаләр дә киң яктыртыла. Бәетләрне, бу нисбәттән, татар халкы тарихының, билгеле бер дәрәҗәдә, турыдан-туры чагылышы дип тә әйтергә мөмкин.

Мөнәҗәтләр һәм бәетләр, җырлар шикелле, киң аһәңле, моңлы һәм матур бизәкләргә төренгән, ләкин алар үзләренә генә хас ритмик үзенчәлекләр белән тулы әсәрләр.

Мөнәҗәтләрне, бәетләрне башкаруда үзенә генә хас үзенчәлек бар. Монда беренче планга тавыш матурлыгы, диапазон киңлеге түгел, ә бәлки сүзләрнең мәгънәсен, аларның эчтәлегенә салынган хисләрне, йөрәк аша үткәреп, тыңлаучыга җиткерә белү чыга. Бу әсәрләрне Габдулла Тукай сүзләре белән әйтсәк, "авызны кәгазь калынлыгында гына ачып" башкару тиешле.

Гасырлар тирәнлегеннән агып килә торган халык иҗаты дигән дәрья -бабаларыбызның тарихын һәм тормыш-көнкүрешен, йола-гадәтләрен һәм рухи дөньясын гәүдәләндерә торган сүз сәнгате, халкыбызның буыннан-буынга күчә һәм тулылана килгән үзенчәлекле хәтере ул. Сурәтле фикерләү белән үрелгән халкыбызның иҗади елъязмасы бүгенге көндә дә дәвамлы булсын дигән ният белән, әлеге җыентыкта бу юнәлештә хезмәт итүче эзләнүчеләрнең, мөгаллимнәрнең фәнни мәкаләләрен һәм рухи мирасыбызның кайбер үрнәкләрен тәкъдим итәбез. Ул үрнәкләрнең сүзләрен һәм ноталарын Казан дәүләт консерваториясенең этномузыкология кафедрасы мөдире, сәнгать фәннәре кандидаты Сәрварова Лилия Илдус кызы һәм сәнгать фәннәре кандидаты Җиһаншина Лилия Хаматхарис кызы әзерләделәр.

*Татарстанның халык артисты*
*Гөлзадә Сафиуллина*

# ИСЛАМ ҺӘМ МУЗЫКА МӘГЪРИФӘТЧЕЛӘРЕБЕЗ КӨЙМОҢ ТУРЫНДА, ЯГЪНИ КӨЙ КӨЙЛӘҮ ХӘЛӘЛМЕ?

Шигырь сөйләү, көйләү, уен кораллары белән уйнау һәм аларны тыңлау хакында Ислам галимнәре арасында каршылык элек тә (X-XI гасырларда) булган һәм төрле фикерләр бүген дә яшәп килә.

Бу мәсьәләгә карата ике капма-каршы фикер хөкем сөрә. Беренчесе – музыканы, ягъни уен коралларында уйнауны, җырлауны тыю яклы. Бу караш тарафдарлары фикеренчә, музыка уен коралларыннан бары тик дәфтә сугу гына хәләл. Әлеге фикер дүрт сөнни мәзхәб тарафдарлары (хәнәфи, мәлики, шәфигый, хәнбәли мәзхәбләре) арасында таралыш тапкан һәм тәкъва мөселманнарда күпчелекне тәшкил итә. Алар үз карашларын Ислам чыганакларына нигезләнеп дәлилли:

**وَمِنَ النَّاسِ مَنْ يَشْتَرِي لَهْوَ الْحَدِيثِ لِيُضِلَّ عَنْ سَبِيلِ اللَّهِ بِغَيْرِ عِلْمٍ وَيَتَّخِذَهَا هُزُوًا أُولَٰئِكَ لَهُمْ عَذَابٌ مُهِينٌ**

Среди людей есть такой, который покупает потешные речи (**لَهْوَ الْحَدِيثِ** «лахва-ль-хадис»), чтобы сбивать других с пути Аллаха безо всякого знания, и высмеивает их (знамения Аллаха). Таким уготованы унизительные мучения. (Коран, 31:6).

وَإِذَا سَمِعُوا اللَّغْوَ أَعْرَضُوا عَنْهُ وَقَالُوا لَنَا أَعْمَالُنَا وَلَكُمْ أَعْمَالُكُمْ سَلَامٌ عَلَيْكُمْ لَا نَبْتَغِي الْجَاهِلِينَ

А услышав праздные речи (لَهْوَ الْحَدِيثِ «лахва-ль-хадис»), они отворачиваются от них и говорят: «Нам достанутся наши деяния, а вам – ваши. Мир вам! Мы не желаем следовать путем невежд». (Коран, 28:55)

Биредәге «ләһвә» сүзе *күңел ачу, уен, шаяру*, «хәдис» сүзе исә *сөйләшү, мөгамәлә* дип тәрҗемә ителә. Шулай итеп, «ләһвәл-хәдис» сүзтезмәсен *шаяру, күңел ачу* дип тәрҗемә итүе, мөмкин. Күпчелек мөфәссирләр (Коръәнне тәфсирләүчеләр) аятьь эчтәлегендәге бу сүзне сөйләү, шигырь һәм музыка дип аңлый. Бу очракта көй көйләү һәм музыка белән бәйле бар нәрсә дә катгый рәвештә тыелган дип исәпләнергә тиеш булып чыга.

Шулай ук бу фикер белән килешмәүче дин галимнәре дә бар. Алар югарыда китерелгән аятьләрдә җыр һәм музыканы тыюга турыдан-туры күрсәтмә юк дип дәлилли.

Көй көйләүне тыю тарафдарлары үз фикерләрен Коръән аятьләреннән тыш, Мөхәммәт пәйгамбәр (СГС) хәдисләре белән дә дәлилли. Мәсәлән, шуларның берсендә:

«Появятся среди моих последователей люди, которые будут пить спиртное (хамр), называя его иначе, над головами будут играть на струнных инструментах и петь певицы. Всевышний опустит под ними землю и сделает их обезьянами и свиньями»[1].

Исламда музыка гомум рәвештә тыелмаган дигән фикер тарафдарлары фикеренчә, алда китерелгән Коръән аятьләре һәм хәдисләрдә көй көйләү белән җырлау вакытында, аларның эчтәлегендә исламда тыелган яисә хәрамга этәрүче сүзләр, гыйбәрәләр вә гамәлләр булса гына, андый музыка хәрам дип санала һәм тыела.

---

[1] Там же

Бүгенге заман ислам галиме Йосыф Кардави әйтүенчә: «Среди развлечений, наслаждающих душу, радующих сердца и слух, является пение. Ислам разрешает пение при условии, что оно не содержит пошлости, непристойности или того, что ведет к греху. Нет ничего предосудительного если музыка не возбуждает. Чтобы создавалась атмосфера радости, рекомендуется петь по случаю какого-либо торжества, как, например, праздника свадьбы и рождения ребёнка».[2] Галим бу фикерне дәлилли торган әл-Бохари, Ибн Маҗа, Мөслими җыентыкларына кергән күп кенә хәдисләр китерә.

Мөселман галимнәре арасында бу фикерне яклаучы буларак Имам әл-Гәзәли, Әбу Бәкр әл-Гәрәби, Ибн Хазм һәм башкалар мәгълүм. XI гасырның мөселман теолог-галиме Әбу Хәмид әл-Гәзәли (1058-1111) «Кеше йөрәгенең иң нечкә серләре»н өйрәнгән китабының 98 нче бүлегендә (426 бит) шигырьләрне, музыканы, җырлауны тыңлау мәсъәләсенә тукталып, түбәндәге хәдисне китерә. Аллаһның Илчесе әйтте: «Мин аларның берсен дә кире какмыйм, әмма аларга әйтегез, алар үзләренең мәҗлесләрен Коръән белән ачсыннар һәм Коръән белән тәмамласыннар».

XIX-XX гасырлар чигендә татар җәмгыятендә дә кадимче дин әһелләре һәм мөсеманнарның бер өлеше җыр белән музыканы гөнаһ дип санаучылардан булган. Шулай ук мөселманнар арасында (бигрәк тә милли татар интеллигенциясе катламында), көчләп чикләүгә каршы торып, көнкүрештә музыка уен коралларын кулланып, көй көйләүчеләр, җырлар башкаручылар да булган. Мәсәлән, Габдулла Тукайның туганы Камил Мотыйгый башкаруында татар халык җырлары, татар мәкаме белән Коръән уку язмалары сакланып калган.

Татар дин галимнәре күпчелеге, җыр белән музыканы башкаруны хуплап, үз фикерләрен югарыда китерелгән дәлилләргә нигезләгәннәр. Шулай ук алар, яшәеш канун-

---

[2] *Юсуф Кардави* Дозволенное и запретное в Исламе / Юсуф Кардави. - пер. с араб. М. Саляхетдинов. – Казань.: Идел-Пресс, 2011. – С. 256

нары нигезе буларак, гармонияле музыканың башлангычын әйләнә-тирә дөньяда һәм кеше табигатенең үзендә тапканнар.

Ризаэтдин Фәхретдиннең «Җәвамигуль-кәлим» шәрхендә аңлаткан шәхси фикере шулайрак: «Әгәр көйләү, ритм булу сәбәпле хәрам диелсә, бу вакытта мондый нәрсәләрне сөйләү һәм тыңлау хәрам икәнлеге хакында шәргый дәлил китерү лязем була. Мондый дәлил китерми торып, шигырьне хәрам дип әйтеп булмый. Бу-бер. Икенче, әгәр көйле һәм ритмлы нәрсәләр хәрам була торган булса, сандугач һәм тургай тавышларын тыңлау да хәрам булып кала. Чөнки аларның тавышлары да көйле бит».

Әдип Коръән һәм Сөннәттә уен коралларында уйнау һәм тавышларын тыңлау хәрам булу хакында аятьь яки хәдис юк, дип дәлилли. Сахих Бохари да (2к. 3-11б; 2к.-91-93): Рәсүләллаһның гает көннәрендә, туй вакытларында уен уйнаудан тыймаганлыгы мәгълүм, ди.

Галим әүлияләр тарихыннан мисал китерә. Даут пәйгамбәргә Аллаһы Тәгалә могҗизадай искиткеч гүзәл тавыш биргән. Ул үзенә иңдерелгән китапны укыганда, кошлар – очуыннан, сулар – агуыннан, җилләр исүеннән тукталган... бөтен дөнья таң калып, аны тыңлаган, аңа кушылып бөтен дөнья Илаһны зикер кылган.

Р.Фәхертдин хезмәтләрендә ислам дөньясы көйләрне әхлак төзәтү һәм гыйффәт тарату хакында корал кылырга тиешле иде, дигән фикерләр әйтелә.

Риза Фәхретдиннең Исламда музыканы тыю-тыймау турында барган дискуссияләр хакында булган нәтиҗәләре икенче галимебез Хәсән-Гата Габәши фикерләре белән үрелеп бара. Диния нәзарәте казые була торып, улы (беренче профессиональ татар композиторы Солтан Габәши) язып калдырган истәлекләре буенча, Хәсән-Гата Габәши үзе дә музыка уен коралларында уйный торган булган, һәм шулай ук улында музыкага сәләт ачылуын белгәч, өйләренә рояльдә уйнарга өйрәтүче укытучыны чакыра.

Үз вакытында тәкъва татар мөселманнарының башта сирәк-сирәк чыгышлар ясап, соңыннан киң популярлык казанган татар җырчысы Камил Мотыйгый-Төхвәтуллинның концертларын күзәтеп, борчылып язган мөрәҗәгатенә Урал төбәге генерал-губернаторы үтенече буенча язылган вазифаи язуында (докладная записка) Хәсән-Гата Габәшинең позициясе мәгълүм. Текстта кулланылган чыганаклар, дәлилләү ысуллары галимнең бу хезмәте ислам гыйлеме кысаларында язылуын раслый. Ул Коръән, Сөннәт текстларын, ислам галимнәре хезмәтләрен тирән анализлап, иләк аша үткәреп, шигырь, җыр, музыканың, нигездә, хәләл икәнен исбатлый.

Бөек татар мәгърифәтче галиме Шиһабетдин Мәрҗани: «Җанга рәхәтлек бирү, кеше рухын сафлык һәм пакьлек дөньясына этәрү – музыканың төп максаты», – ди. Ш.Мәрҗани үзе дә. Мәдрәсәсендәге шәкертләрен ияртеп, табигатькә алып чыгарга яраткан һәм аларга табигать хозурында тәэсирләнеп, әдәбият, сәнгать, шигърият турында чыгышлар ясаган. Шәрык шигъриятенең гүзәл үрнәкләрен сәнгатьле итеп укырга яраткан, сәнгатькә һәм сәнгатькәрләргә соклануын яшермәгән.

Каюм Насыйриның «Фәвакиһел җөләса» әсәренең 30 нчы бүлегендә мондый фикерләр бар: «Хәкимнәр матур көйнең җан азыгы булуын раслыйлар. Ул акылны сафландырыр, зиһенне нечкәртер, табигатьне йомшартыр, мәрхәмәтлене мактатыр, курыкканны батырлатыр, саранны юмартландырыр, дигәннәр. Музыка ул кешенең тәненә һәм әгъзаларына тәэсир итә... матур тавышларның тыңлаучының кан йөреше өчен дә тәэсире бар.

Коръәннең бер сүрәсендә «Ахырзаманда сәләтсездән сәләтлене аера алмаслар, ахмаклар җаваплы урыннарга үрмәләр...» дигән юллар бар. Бу мәсьәләгә карата шулай ук үз заманында дан казанган «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе җитәкчесе, «Дин вә әдәб» журналы мөхәррире, Россия мөселманнарының бердән-бер сайланып билгеләнгән мөфтие

Галимҗан Барудиның да көй көйләүнең хәрам түгеллеген исбатлаган фикерләре булуы мәгълүм.

Габдулла Тукай да үзебезнең хакларыбызны алуда тартышырга, гафил булмаска куша. Аңа якын килергә теләүчеләр халыкка әүвәлдән файда китерүче, рәхимле вә әдәп-инсафлы булсын, милләт өчен җанын вә малын кызганмасын, дигән. Тукайның яшәү рәвеше, иҗади фикерләре дә Ислам кануннарына нигезләнгән һәм шул нигездә ул үз халкына хезмәт итә. Г.Тукай җыр-көйләр турында әйткән һәм төрле уңайдан язылган мәкаләләрендә, музыка сәнгатебезгә кагылышлы мәсьәләләргә карата иҗатының асыл рухын сиздереп, әтрафлы фикерләрен белдергән, халык җырларын җыю белән шөгыльләнгән, хәтта шушы темага лекцияләр дә укыган, җыр-моңны нечкәләп аңлаучы да булган. Безгә «Туган тел» гимнын мөкатдәс мирас рәвешендә калдырган Тукай татарны милли музыка сәнгатендә дә тәрәккый югарылыкта күрергә теләгән.

Моннан 100 еллар элек халык көй-моңнары яшәүчәнлеге турында язганда, әдипнең: «Милләтебез диңгезенең энҗеләре төптә ятып, ул-булары гына өсткә калка шул», – дип борынгы көйләрнең халык хәтереннән җуела баруына күңеле сыкрый. Шагыйрьнең васыятьнамә формасында әйтелгән сүзләре нәкъ бүгенге көндә әйтелгән күк. Тукай халкыбызның рухи мирасы үрнәкләре – энҗе-мәрҗәннәренең онытыла баруы һәм аларны чын безнеңчә – халыкча итеп башкару алымнарының башка чит халыкларныкына охшарга тырышуга әйләнә баруын җинаятьь итеп карарга кирәклеген ассызыклый.

Тукайның җырлау рәвешебез турындагы төпле фикерләре бүгенге көндә дә бик актуаль: «... Безнең бер көйне татар булмаган бер кешедән җырлатсаң, көемезнең алтынын кояр шикелле тоела... Халык җырлары үзенең бөтен мөһмәлияте вә җитешсезлекләре белән бергә, әлбәттә, үземезгә генә сөекле булырга тиеш һәм сөекле дә... Шулай, һәр кош үз тавышы белән ләззәтләнә».

«Җыр-көй һәм аны башкару – һәр милләт өчен үзенчәлекле әйбер, татар җырлавында да үзенә генә хас йолалар, үзе яраткан алымнар, манералар бар, – ди күренекле әдибебез Нәкый Исәнбәт. – Андагы моң техник момент кына түгел, ул халык җыр-моң традициясе белән дә бәйле бер нәрсә. «Моң»ны кайгы-сагыш мәгънәсендә аңларга ярамый. Моң ул халыкның күңел ихтыяҗын үти»... дип үз фикерен белдерә.

Җыр башкарганда чама белмәү, Изге Китапны да артык «бизәп» уку, бугаз киереп көчәнеп җырлау, үгез кеби мөгерәү, натураль җылап, борын авазы белән һәм башка җырлау рәвешенең югары кимәлдә түгеллеген күрсәтүче факторлар – бүгенге эстраданың яшәү ысулы. Хәтта Аллаһы Тәгалә әмерендә: «Коръәнне көйләп, тәртибен китереп укыгыз»,– диелгән. Пәйгамбәребез (салләллаһү галәйһи вә сәлам) дә үзенең өммәтен: «Коръәнне матур (!!!) тавышларыгыз белән бизәгез»,– дип өйрәткән. Азгын җырлар башкару – гөнаһ, ә музыка кораллары кулланмыйча көйле мөнәҗәт әйтергә ярый... һ.б.

Сүзебезне Г.Тукайча тәмамлыйк: «Зинага чакыра торган музыка хәрам булса да, алга китәргә, тәрәккыйга чакыра торган музыка гүзәл, хәтта мәҗбүр үктер..., тәрәккый заманында мәҗлесләрдә халыкны гыйлемгә, сәнгатькә өндәсәләр, яхшы булыр иде. Безнең милләт чын мөхәррирләргә... яңа-яңа милли шигырь, музыкаларга вә гайреләргә мохтаҗ... Без ул милләткә әдәбият гөл-сулары сибик... җан рәхәте булган (!) музыкалар белән дәртләндерик...!»

*Зөлфәт хәзрәт Габдуллин,*
*«Мөхәммәдия» мәдрәсәсе проректоры*
*Филүсә Арслан, сәнгать фәннәре кандидаты*
*Резедә Сафиуллина,*
*филология фәннәре кандидаты*

# КӨЙЛӘП УКУ СӘНГАТЕ

Көйләп уку сәнгате татар халкында Урта гасырлар дәверендә зур үсеш ала. Башлангыч адымнары исә борынгы төрки заманнардагы чичәннәр, җыраулар иҗатында ук башланып китә һәм Урал-Алтай мәдәни даирәсе традицияләренең төрле вариантларын чагылдыра. Идел-Урал төркиләре, шул исәптән, төбәкнең мәдәни мәркәзе булган Болгар илендә яшәгән халык, ислам сәнгате даирәсенә кергәч, эпик әсәрләрне башкарганда кулланылган алымнар нигезенә фарсы-гарәп цивилизациясенә хас көйләп уку традицияләрен дә куша. Бу кушылыш татарларга хас көйләп уку үзенчәлекләрен барлыкка китерә.

Кадими классик шигъри әсәрләрне мәкам белән башкару сәнгатен хәзерге вакытта югалта төштек сыман, әмма аны яңарту кирәклеген һәркем дә аңлый дисәк, ялгышмабыз. Шуңа күрә бу сәнгатьнең нечкәлекләрен яңадан ачып, өйрәнеп, хәзерге мәдәнияткә кертү өчен күп эшләр башкарасы бар әле. Зур казанышыбыз һаман да халкыбыз арасында традицион өслүб сыйфатларына таянган хәлдә яшәп килә. Әлбәттә, ул көчсезләнгән, әмма үзенең яшәешен югалтып бетермәгән әле. Бигрәк тә классик шигърият традицияләрен һәм аның белән тыгыз элемтәдә булган музыкаль хосусиятләрен, шул исәптән, гаруз системасын чагылдырган метрик (вәзен) һәм ритмик (икагъ) сыйфатларын күздә тотабыз. Татарларда әүвәлге заманнардан ук гаруз сәнгатен өйрәнүгә зур игътибар биргәннәр. Моны нинди фактлар исбатлый соң? Халык

арасында үткәрелгән археографик экспедицияләр барышында Урта гасырларга караган гаруз теориясенә багышланган кулъязмалар еш табыла. Шундый хезмәтләр арасында, мәсәлән, гаруз теориясен тасвирлаган Габдерахман Җәми рисаләсе һәм гарәп, фарсы, иске татар телләрендә язылган башка авторларның хезмәтләре дә бар.

Татарлар арасында китап бастыру дәвере башлангач, күп кенә популяр кулъязмалар аерым рисалә, китапчыклар басма рәвешендә чыга башлый. Шулай XIX йөз азагы – XX йөз башында «Гыйльме гаруз нәмүнәсе» (Оренбург, 1906), «Шигырь бизмәне. Гаруз» Андалуси [хезмәтенең] тәрҗемәсе (Казан, 1909) кебек рисаләләр шигырь язу белән мавыккан яшь авторлар арасында аеруча популяр булалар.

Соңгы вакытта туган вазгыятьтән күренгәнчә, сәнгатебезнең бу төре җәмгыятьтә зур кызыксыну уятты. Көйләп уку сәнгатенә караган шигъри текстлар, төрле мәкам нечкәлекләре, аларны ничек итеп дөрес көйләү, уен коралларына кушылып башкарылу үзенчәлекләре турындагы мәгълүмат, бер яктан, турыдан-туры дин әһелләренә кирәк булса, икенче яктан, милли музыка тарихын һәм аның теориясен өйрәнүче галимнәр, шулай ук җыр һәм музыка өлкәсендә иҗат итүче үзешчән яки профессиональ дәрәҗәдәге композиторлар, башкаручылар да алар белән кызыксына башлады. Бу күренеш, әлбәттә, җәмгыятебездәге әлеге ихтыяҗны чишүгә юнәлгән социаль заказ барлыгын ачык күрсәтә.

Шунысын ачыклап үтик: көйләп уку сәнгате белән бәйле шигъри-вокаль әсәрләр әүвәлгедән үк ике тармакка бүленеп үскән. Беренчеләре дини эчтәлекле булса, икенчеләре исә дөньяви, бары тик ислам этикасы, эстетикасы аша үткәрелгән, турыдан дин белән бәйле булмаган сюжетларга корылган булган. Әмма бу ике тармак та өслүб буенча бербөтен күренеш тәшкил иткән. Хәзерге заманда исә дини эчтәлекле әсәрләр башкару традициясе күбрәк сакланган.

Хәзерге яңарыш дәверендә традицион рухи байлыкларга игътибар арта бара. Төрле дини мәҗлесләрдә, мәүлид, рамазан айларында, башка дини вакыйгаларда, әүвәлдән килгән йола буларак, килешле мәкам белән үгет– нәсихәт, дин тарихындагы күренекле шәхесләргә багышланган касыйдә, газәл, робагый һәм башка жанрларда иҗат ителгән шигъри әсәрләр башкару гадәте дәвам итү мәгъкүл күрелә. Мондый башлангыч сәнгать әһелләре арасында да аерым бер урын алып тора. Мәкам белән уку тәҗрибәләре, ягъни бәет, мөнәҗат телевидение һәм сәхнәләрдән ишетелә. Хәзерге вакытта көйләп уку сәнгате яңарыш ала дидек. Атап үтелгән юнәлешләр XX гасыр башындагы хәлләреннән аермалы буларак, үзенә генә хас, яңа сыйфат белән, яңа шартларда үсешен дәвам итәләр. Шуларны күзаллап карыйк.

Беренче торыш шул: көйләп уку сәнгате олы буын вәкилләре арасында, үзенең иляһи һәм рухи вазифаларын беренчел сыйфаттагы шартларда, ягъни табигый дәвамчылык сыйфатында, гади көнкүреш шартларында, элеккеге инерцион көчләргә генә таянып дәвам итә. Монысын да исәптә тотыйк: бүгенге көндә бер генә татар мәдрәсәсендә дә төркитатарча шигъри текстларны көйләп укыту кагыйдәләре, өслүб таләпләре махсус программалар белән өйрәтелми, чөнки аны укытырлык, яисә аны кирәксенгән мөгаллимнәребез дә әлегә бик күренми. Мондый мәгълүматлар бирү гамәлләренең туктатылуы 1917 елдан соң традицион татар мәгариф системасының мәҗбүри рәвештә өзелү нәтиҗәсендә барлыкка килде.

Икенче торыш: көйләп уку сәнгате, аңа хас өслүб алымнары – бүгенге көннең популярлаша барган жанры. Ул яңа барлыкка килгән сәхнә сәнгате феномены булу алдында тора. Бу очракта исә ул концерт законнарына буйсынып, үзенең тәрбияви эстетик вазифаларын турыдан туры, табигый ки, дини функцияләр белән бәйле булмаган, лирик төсмерле

шигъри әсәрләр башкару юнәлешендә алып барырга тиешле була.

Атап үткән ике юнәлешкә дә яңарыш, үсеш алу өчен дөрес юл бирү зарур. Шуңа күрә, көйләп уку сәнгатен алга таба үстерү өчен алда шактый күп мәсьәләләр бар. Шундый мәсьәләләрнең берсе – дәвамчылык механизмының нык какшаган булуы һәм аны төзәтү юлларын эзләү. Мондый хәлгә төшүнең сәбәпләре күп, шуларның берсенә тукталыйк.

Яңа дәвер татар мәдәнияте үсеше чорында (XIX йөз уртасы – XX йөз башы), Урта гасырларда үсеш алган классик ислами болгар-татар сәнгатебез (язма шигъриятебез һәм элитар музыка традицияләре) тәмам хәлсезләнә. Җәдитчелек дәвере сәнгатенә ул исә үтә зәгыйфь хәлдә генә керә ала. Классик ислами музыка кораллары: танбур, дәф, гыйжжык, канун һ.б. онытыла, юкка чыга һәм кулланудан төшеп кала. Көйләп уку бөтенләй юкка чыкмый, әмма аның кулланыш даирәсе чикләнә, һәм ул фәкать хатын-кызлар сәнгатенә әверелә. Пролетар инкыйлабтан соң иске татар (классик) вокаль-шигъри сәнгатебез бөтенләй югалуга дучар ителә. Күрәбез ки, җидти тарихи сәбәпләр аркасында бу төр сәнгатебезнең үсешендә күләмле өзеклекләр пәйда булды.

Көйләп уку, мәкам белән башкару сәнгатенең кагыйдәләрен белүчеләр әлегә бар дисәк тә, алар аз, һәм көйләп укуны табигый, классик рәвештә белгән кешеләр тагы да азрак, алар да инде китеп бара. Җитмеш яшьтән арткан кешеләр арасында да алар сирәк табыла. Әлбәттә, хәзер халыкта Көйләп уку сәнгате тарихындагы өзеклекне ялгау омтылышы күзәтелә. Бу борынгы сәнгатебездәге өзеклекне бетерүнең үтемле чарасы – балаларга өйрәтә башлау. Көйләп уку рәвеше халык арасында нәтиҗәле булсын дисәк, абруй казанган остазларның үз сәнгатьләре турында балаларга өйрәтүе тора. Чөнки остазлык халкыбыз арасында кадимнән булган һәм ул беркайчан да бөтенләйгә өзелмәде. Мондый

эшнең матди һәм рухи куәтләү чараларын таба алсак, бу эшнең азагы яхшы нәтиҗәләр бирә алыр иде.

Танылган остазларның шәкерте булу балаларга гына түгел, тәҗрибәле башкаручыларга да зыян итмәс, чөнки *озын көй, авыл көйләрен җырлау, такмаклар әйтү* өслүбенә күнеккән кешегә *мәкам белән көйләп уку* нечкәлекләрен өйрәнү җиңел түгел. Билгеле ки, милли *җыр сәнгатенең* катлаулы һәм югары баскычларын белгән хәлдә, *көйләп уку сәнгатенә* дә мелизмнар кертергә, сырлап-бөдрәләтеп башкарырга ярамый.

Игътибар итсәк, классик остазлык мәктәбен үтмәгән килеш көйләп укучыларның тыңлаучылар калебенә үтеп, гадәттә, иляһи бер тәэсир итүләре сирәк була. Монда шуны да искәртергә кирәк: көйләп уку өчен, башкаручы үзе дә тиешле дәрәҗәдә иляһиятле бер зат булырга, рухи тәрбия алырга, халык алдында чыгышлар хокукы алыр өчен остазыннан фатиха алырга тиеш.

Остаз белән өйрәнүче шәкерт арасындагы укыту һәм укуның үзенә генә хас формасы булырга мөмкин. Ягъни, нәзария ягыннан, шигырь һәм музыка теориясеннән җөйләп уку (мәкам белән уку) сәнгатенә бәйле гомуми кагыйдәләр бар.

Татарның иске классик музыка сәнгате белән бәйле төшенчәләре Идел буе төркиләре телендә чыгышлары буенча гомум ислам мәдәниятендә кулланылган, шигърият-музыка өлкәсенә караган уртак терминнар, төшенчә атамалары, гадәттә, ике төрле мәгънәдә булулары белән билгеле. Аның берсе Урта гасыр дәверендәге татар җәмгыятенең югары катлам даирәләренә караган классик мәгънәсен аңлатуны чагылдыра. Икенчесе исә, гади көнкүрештә, фольклор дәрәҗәсендә булып, мәгънәсе еш кына гадиләшкән, җирле сәнгать традицияләре аша үтеп, этник мәдәният өлеше булып киткән. Шуңа күрә мондый атамаларның татар мәдәниятендәге хәлен-халәтен күз алдына китерү өчен, аларның ике төрле мәгънәсен дә исәпкә алу зарур.

**Мәкам.** Бу атама Шәрык дөньясында шактый мәгънәләргә ия. Аның чыгышына, эчтәлек сыйфатларына багышланган фәнни дискуссияләр күп дәверләргә сузыла. Бу күпкырлы мәгънәләр манзарасы эчендә татар халкының «мәкам» төшенчәсенең урыны да бар. Татар музыка мәдәниятендә «мәкам» атамасы дини һәм дөньяви сәнгать күренешләрен белдерә.

Бу атама халык иҗатында да үз чагылышын тапкан. Мәсәлән, «Мәкам – ярты гыйлемлек» (монда иске дәвер классик шигъри әсәрләрне матур итеп көйләп уку сәләте турында сүз бара). Бу мәкальдә «мәкам» төшенчәсенә, иске татар классик шигъри-музыкаль сәнгатендәге «гыйльми» өслүб кыйммәтенә халыкта булган уңай мөнәсәбәт чагыла һәм ул (исламга кадәр барлыкка килгән) гади ил (этник) көй-җырларын башкару сәнгатенә чагыштырма рәвештә күпертеп куела.

Халыкта борынгы заманнарда ук Коръән, башка дини, дөньяви шигърият әсәрләрен килешенгән мәкам белән көйләп укый белгән хафизлар, мәкам остазлары хөрмәт һәм дан казанганнар. Бөтен дөньяга билгеле галим һәм дин белгече Ш. Мәрҗани да, «мәкамәт сәнгатенең кыйммәтен белгән кешеләр, яхшы көйләп укый белгән башкаручыны тыңлар өчен, хәтта бик ерак урыннардан да килә торган булганнар», дип яза.

Кагыйдә буларак, танылган мәкамче-остазларның сәнгатьләрен өйрәнә торган шәкертләр, өйрәнүчеләр аның мәктәбен дәвам иткәннәр. Мондый остазларның исемнәре, аларның даннары еракка таралган һәм хөрмәт ителгән. Ш. Мәрҗани, мәсәлән, шундый танылган мәкамче булган Сембер губернасының Курмыш өязе, Петряксы авылында яшәгән мелла Таһир бине Сөбхан әл-Микрый (1775–1864) турында яза. Коръәнне көйләп укыганда, ул зур осталык һәм нәфисәт белән, Идел буе тирәләрендә популярлык казанган «Котдус Шәриф», «Хәрәмин», «Мисыр» мәкамнәрен баш-

кара торган булган. Шулай ук, үзе иҗат иткән мәкамнәре белән дә дан казана. Аларны Коръән укыганда гына түгел, башка классик шигъри әсәрләр көйләгәндә дә кулланган[3]. Ш. Мәрҗани фикере буенча, аның башкарган мәкамнәре ислами классик сәнгать әсәрләренә таләп ителгән шәкел һәм башкарылыш кагыйдәләренә туры килгән.

Әлеге мәкам белгече мелла Таһир бине Сөбхан үзенең остазы итеп мелла Вәлиэтдин бине Хәсән әл-Багдадины (1775–1831) санаган. Бу остаз Багдад шәһәрендә туа, Һиндстан, Хөрәсән, Урта Азиядә (Бохара) горбәтлектә йөргәннән соң, язмышы аны Урта Идел буйларына китерә. Монда ул мәкам остазы буларак шөһрәт казана һәм үзенең сәнгатен күпсанлы шәкертләренә тапшыра. Вәлиэтдин Багдади тормышының соңгы дәверендә Оренбург губернасындагы Каргалы авылында яши, шунда вафат була һәм Каргалы зиратына дәфен ителә.

Халык телендә көйләп уку сәнгатен «мәкам белән уку» диләр. «Мәкам» бу очракта ислам традицияләре белән бәйле көйле сөйләмгә якын уку ысулын белдерә. Халыкта танылган Коръән-хафизлар турында: «Аның мәкаме яхшы», – диләр.

Халык арасында, элеккедән килгән йола буенча, аерым хуҗалар тарафыннан махсус оештырылган «Коръән уку», «Коръән хәтем» мәҗлесләре шактый еш була. Алар саваплы гамәл булып кабул ителә. Мондый мәҗлесләрдә Коръәннән башка, иляһи шигырьләр җыентыкларын тәшкил иткән «Мөхәммәтия», «Бәдәвам», «Бакырган», «Кыйссаи Йосыф» китапларындагы әсәрләрне мәкам белән көйләп укыйлар.

Халыкта «көй» һәм «мәкам» төшенчәләренең аерма чикләрен төгәл һәм анык итеп белүчеләр бихисап. Алар «көй» төшенчәсенә, башлыча, «ил җырлары көе» мәгънәсе хас дип аңлаталар. «Мәкам» төшенчәсенә исә «Коръән һәм

---

[3] *Марджани Ш.* Мөстафадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар (Казан вә Болгар хәлләре турында файдаланылган хәбәрләр). – Казан : Татар, кит. нәшр., 1989. 277, 337, 338 б.

язма шигърият әсәрләре көе», мәсәлән, робагый, касыйдә, газәл көйләре мәгънәсе туры килә дип белдерәләр.

Бу кагыйдәдән чыгармалар да бар. Пермь, Екатеринбург, Чиләбе, Төмән өлкәләрендәге уен коралларында башкарыла торган ил көйләрен (этник музыкада) «мәкам» (Төмән өлкәсендә «могам») дип атау күренеше бар. Мәсәлән, «Ат чабыштыру мәкаме»[4], Себер татарларында тагы да «Шәйтан куу мәкаме» (Чир сулышын куу көе), «Койгылык мәкаме» (тычканнар тотып туклана торган кечерәк кенә кошка багышланган тасвири көй).

**Уку. Көйләп уку.** Халык арасында әлеге атамалар киң таралган һәм өстәрәк телгә алынган «мәкам, мәкам белән уку, китапхан, ханәндә» төшенчәләренә эчке сыйфатлары белән якын торалар. «Уку» атамасы «мәкам» һәм «ханәндә» кебек үк, күп кенә мөселман халыкларында кулланыла. «Уку» төшенчәсе гадәттә ике мәгънәдә була. Беренчесе – гадәти мәгънәдәге «китап уку». Икенчесе исә – «шигъри әсәрләрне көйләп уку». Шул ук вакытта кайбер детальләрдә аермалыклар да булырга мөмкин.

«Уку» атамасы татар халкының вокаль сәнгатендә «җырлау», «җыр җырлау» төшенчәсе белән туры килми, чөнки «җырлау» атамасы ил көйләре (этник вокаль сәнгате) өлкәсендәге башкаручылык сыйфатлары белән бәйле. Шуңа күрә халык арасында бер яктан «җырлау», икенче яктан – «көйләп уку», «мәкам белән башкару». Бу атамаларны буташтырып куллану күренеше тәрбиясезлек һәм килешсезлек булып саналган. Чөнки әлеге атамалар төрле өслүби катламнарны чагылдыралар: авыз иҗаты белән бәйле ил җырлары сәнгатен һәм Урта гасырларда ук барлыкка килгән элитар язма шигърият белән бәйле мәкамәт, көйләп уку сәнгатен тәшкил итәләр. Шул ук вакытта узган дәверләрдә булган әлеге өслүби катламнарның табигый рәвештә бер-берсенә йогынты ясаган процесслар булуын да инкяр итмибез. Ягъ-

[4] *Нигъмәтҗанов М.Н.* Татар халык җырлары. – Казан: Татар. кит. нәшр, 1976. – 163 б.

ни ил көй-җырлары һәм мәкамәт сәнгате сыйфатлары бер-берсенә күпмедер дәрәҗәдә тәэсир иткәннәрдер.

Әлеге очракта, татар халкында кулланылган атамалар белән бәйле рәвештә борынгы, исламга кадәрге дәверләрдә кулланылган көйле сөйләм традицияләренең кайтавазларына, ягъни язма шигърият белән генә түгел, язу чорына кадәрге милли мираста булган элементларга, җырау, чичәннәрнең эпик әйтеш сәнгатенә дә игътибар итәргә кирәк. Бу ике юнәлешне аерым өслүб итеп өйрәнү мөһим, әмма бу мәсьәләнең махсус рәвештәге фәнни яссылыкта куелышы әле үзенең сәгатен көтә. Без бу мәсьәләнең кайбер якларына гына туктыйбыз.

**Әйтү. Әйтеш.** Татар музыкасы яссылыгында «әйтү» атамасы еш кулланыла һәм үзара аерыла торган берничә мәгънәгә бүленә:

а) «бәет әйтү», «мөнәҗәт әйтү» гыйбарәләрен гади халык тарафыннан ишетергә мөмкин, әмма алар классик төшенчәләр булган «көйләп уку» атамасына караганда бераз сирәгрәк яңгырый. Мондый күренеш «әйтү» атамасының килеп чыгышы белән бәйле, һәм ул, һичшиксез, үзендә исламга кадәрге авыз иҗаты шигъриятендәге «көйле әйтеш» элементларын чагылдыра. Бу атаманың төп мәгънәсе «уку» түгел, «әйтү» төшенчәсенә, ягъни авыз иҗаты белән бәйлелеккә юнәлгән, һәм ул нәкъ шул мәгънәсе белән хасиятле дә;

б) моннан тыш, «такмак әйтү» гыйбарәсенең халыкта киң кулланылганы билгеле. Ул исә, көйле сөйләм ысулы белән такмаклап, җыр текстларын килешле бер ритм кысасында әйтү ысулы белән хасиятле. Әлбәттә, бу атама авыз иҗаты белән бәйле ил сәнгатенә якынлыгын ачык күрсәтә.

# ТАТАРНЫҢ ИСКЕ КЛАССИК МУЗЫКА СӘНГАТЕ ЖАНРЛАРЫ

Татар мәдәниятендә язма шигъри традицияләр үсеше мең елдан артык дәверне үз эченә ала. Урта гасырлар чорына хас язма шигърият жанрларының сыйфатларын тикшерүгә багышланган башлангыч С.Г. Рыбаков исеме белән бәйле. Аның тарафыннан, беренче тапкыр буларак, бәет, мөнәҗәт, касыйдәләрнең ноталары һәм шигъри текстлары матбугатта нәшер ителде. Авторның бу жанрларны гомумислами язма шигърият күренешләре итеп, аларны авыз иҗаты белән бәйле этник сәнгатьтәге җыр иҗаты катламыннан аерып конкретлаштыруы билгеле.

Әлеге сәнгать катламын тикшерүчеләр С.Г. Рыбаков, В.М. Мошков башлаган эшне дәвам итеп, татар композиторы С. Габәши аңа үз өлешен кертә. «Милли моңнар, төрки-татар көйләре»[5] җыентыгына ул 1909–1920 елларда язып алган егермедән артык бәет көйләренең ноталарын туплаган.

1917 елдан соң Россиядә, акрынлап, вульгар-социологик идеяләр өстенлек ала, һәм татар халкының иске дәвер классик музыка, шигърият сәнгатен тикшерү өлкәсендәге фән торышына зур зыян килә. Нәтиҗәдә, традицион татар сәнгатен тикшерүчеләр татар халкының Урта гасырларга караган

[5] Милли моңнар, төрки-татар көйләре (С. Габәши язмалары буенча) / Төз.-автор Г.М. Макаров. – Казан: «Мәгариф», 2002. – 207 б.

мәдәни мирасының эчтәлек хосусиятләрен өйрәнүдән баш тартырга мәҗбүр булалар.

1930 еллардан соң С. Габәшинең һәм шул чордагы башка авторларның музыка фольклорына багышланган хезмәтләрендә инде гомумислами музыкаль-шигъри әсәрләрдән дини һәм дә дөньяви эчтәлекле, мәсәлән, зикер, касыйдә кебек жанрларга махсус багышланган аналитик тикшеренүләр бөтенләй үткәрелми һәм кертелми башлый.

Күз уңында бары тик халык арасында гына бик популяр булган бәхетсез мәхәббәт, фаҗигаләргә багышланган бәетләр генә кала. Аларга тулысынча күз йомарга мөмкин түгел иде шул. Әмма фольклорчылар тарафыннан сыйнфый күзлектән карап сайланылган, эчтәлекләрендә социаль конфликтлар, ачы язмышлар, сатирик яисә тарихи сюжетлар чагылган бәетләр генә язылып алып тикшерелә иде.

1960 еллар башыннан, татар музыкасының ислами классик сәнгате белән бәйле катламын өйрәнү, фольклорчы һәм музыка белгече М.Н. Нигъмәтҗанов хезмәтләрендә үсеш импульсы ала. Дөрес, аның тарафыннан исламга карата бераз тискәрерәк дежур бәяләмәләр әйтелде, әмма алар совет идеологиясе өлкәсендә эшләүче җаваплы хезмәткәрләрнең каршылыгын җиңәр өчен һәм ислами татар сәнгатенең бер микъдар өлешен булса да музыка белеменең фәнни даирәсенә кертү өчен кирәк иде. Татар музыка белемендә кулланылган «бәет» һәм «сада» жанрлары исемлегенә М.Н. Нигъмәтҗанов тарафыннан музыкаль фән даирәсенә иляһи шигърияттән «мөнәҗәт» һәм, авыз иҗатының лиро-эпик жанры буларак, «хушаваз» төшенчәләре кайтарылды. Галим тарафыннан көн тәртибенә шулай ук Коръән мәкамнәрен өйрәнү кирәклеге һәм татар музыкасының Урта һәм Якын Шәрыкта яшәгән мөселман халыклары сәнгатьләре белән үзара бәйләнеш дәрәҗәсен тикшерү мөһимлеге турындагы фикер әйтелде.

Безнең тарафтан 1977 елдан башлап бүгенге көнгә кадәр җәй саен татар авылларында фольклор экспедицияләре

үткәрелде. Алар барышында җыелган материаллар ислами музыка сәнгате теориясе һәм тарихы чагылган китаплардагы мәгълүматлар белән чагыштырылып өйрәнелде. Мондый чагыштыру нәтиҗәләре бәет, мөнәҗәт, хушаваз һәм башка төрле музыкаль-шигъри жанрлар турында булган күзаллауларны тагы да киңәйтергә мөмкинлек бирәләр.

## Бәет

Бу атама татар музыкасы һәм шигъриятендә ике мәгънәдә кулланылырга мөмкин:

– беренчесе – «бәет» («бәйт»). Бу атама классик шәрык шигъриятендә теләсә нинди шигъри жанрдагы «икеюллык» мәгънәсен аңлата, һәм ул төгәлләнгән фикер белдерергә тиеш. Мондый бәетләр мәснәви, касыйдә, газәл һәм башка шигъри жанрларның нигезен тәшкил итә. Әлеге жанрларның күләме бәетләр саны белән исәпләнә;

– икенчесе татар фольклористикасында традицион татар сәнгатендәге, Урта гасырларның соңгы дәверендә барлыкка килгән фольклор жанрын белдерә һәм билгеле күләмдәге бербөтен сюжетка бәйле музыкаль-шигъри әсәр калыбын тәшкил итә. Әлеге «бәет» атамасының һәм жанрының барлыкка килүе, һичшиксез, татар җәмгыяте тормышындагы актуаль вакыйгаларга кагылышлы язма музыкаль-шигъри әсәрләр иҗат итү традициясе белән бәйле. Фольклорлашкан бу әсәрләрнең авторлары, гадәттә, җәмгыятьнең язма шигърият сәнгатен белгән урта катлам вәкилләре булган. Күпчелек бәетләр гади көнкүрештә, халыкның үткән тарихындагы фаҗигале хәлләрне, каһарманлык кылу яисә көлкеле вакыйгаларны тасвирлыйлар. Бәет жанрының калыплашуы катлаулы һәм бертөрле генә түгел. Аның башлангычы язмачылыкка кадәрге традицияләргә барып тоташа, әмма нигезендәге төп сыйфатларын язма шигърият кануннары тәшкил итә. Мәсәлән, конкрет рәвештә билгеле шәхесләр,

якын кешеләрнең вафатын, фаҗигале үлемнәрен тасвирлаган, шул кешеләр хакында матәм хисләрен күрсәткән шигырьләр классик ислами шигъриятендәге мәрсия жанры белән бәйле булуына шик тудырмый.

Әлеге жанрның классик мисаллары шагыйрь Г. Утыз Имәни иҗатында ачык чагыла. Аның мәрсия жанрындагы әсәрләре хатыны Хәмидәгә («Мәрсияи Хәмидә зәүҗаты Габдерәхим Болгари»), шагыйрьнең улы Габденнасыйрга («Мәрсияи Габденнасыйр вэлэде Габдерәхим»)[6] багышланалар һәм югары дәрәҗәдәге шигъри нәфисәтлекләре белән аерылып торалар. Кабатлау өчен матур үрнәк булырлык шундый ук бер мәрсия Мифтахетдин Акмулла (1831–1895) тарафыннан Ш. Мәрҗани вафатына багышлап язылa («Дамелла Шиһабетдин хәзрәтенең мәрсиясе»)[7].

Безнең уебызча, татар мәдәниятендә Урта гасырларның соңгы дәверендә барлыкка килгән тарихи үзгәрешләр нәтиҗәсендә, халыкның гади көнкүрешкә хас үзаңында классик шигърият кануннары сыйфатлары, шул исәптән классик мәрсия яза белү дә, йомшаган һәм акрынлап югала төшкән. Халык мохитендә, әлеге әсәрләрнең эчке бүленеш сыйфатларыннан чыгып, мәрсия, мәдхияләргә аермыйча, аларны гомумиләштереп, бер төшенчә рәвешендә «бәет», ягъни «берәр вакыйгага багышланган шигырьләр» дип йөртә башлау гадәткә кергән булса кирәк. Бәлки, башлангыч нигезендә «бәет» атамасының мәгънәсен «шигырьләр» төшенчәсе белән дә аңлату ялгыш булмас иде. Мәсәлән, «Суга баткан Гайшә бәете»н – «Суга баткан Гайшә турындагы шигырь» дип, «Пугачау бәете»н – «Пугачау турындагы шигырьләр» дип, чөнки «бәет» атамасының беренчел мәгънәсе нәкъ менә шигырь формасын белдерә. Димәк ки, бәет жанры, һичшиксез,

[6] *Габдерахим Утыз Имәни әл-Болгари*. Шигырьләр, поэмалар / Төз. Ә. Шәрипов. – Казан, 1985. 32–35 б.

[7] Татар поэзиясе анталогиясе. I китап. Казан, 1992. 341, 342 б.

чагыштырмача рәвештә «фольклорлашкан» иске татар язма шигърияте белән бәйле.

## Робагый (әрбагый, ырбагый)

Татар халкы яшәгән күп кенә төбәкләрдә, шул исәптән Казан арты районнарында (Балык Бистәсе, Мамадыш, Биектау, Арча), «бәет» һәм «мөнәҗәт» төшенчәләреннән тыш, традицион мәдәнияттә бүгенге көнгә кадәр классик Шәрык шигъриятендә дә билгеле булган «робагый / әрбагый» атамасы еш кулланыла. Шәрык шигъриятендә «робагый» (рубаи) атамасы фикере тәмамланган фәлсәфи эчтәлекле дүрт юллы шигырь формасын аңлата. Классик робагый рифмалары а а б а, кайвакытта а а а а, а б а б, а б б а, а а б б. Робагыйларда «рәдиф» тә, ягъни һәр дүртьюллыкта кабатлана торган «әйтмеш» сүзе дә актив кулланыла. Бу жанр Шәрык илләрендәге күпчелек халыкларның музыкаль-шигъри иҗатында бар. Аларны анда музыка коралларына кушылып башкаралар.

Татар халкының традицион мәдәниятенә хас робагыйларның шигъри һәм музыкаль эчтәлек сыйфатлары, башкару хосусиятләре хәзерге көнгә кадәр аерым рәвештә тикшерелмәгән килеш кала. Әмма бүгенге көн фольклор экспедицияләре материалларыннан шул күренә: авыллардагы этник мәдәнияттә робагый төшенчәсенең мәгънәсе андагы көнкүреш бәет төшенчәсе белән бик якын. Мәсәлән, «бәет чыгару» һәм «робагый / әрбагый / ырбагый чыгару» гыйбарәләре бер-берсенә тәңгәл. Мондый күренеш күпчелек авылда яшәүчеләр җавапларында теркәлде[8].

Бу төшенчә фольклор әсәрләре телендә дә чагыла. Мәсәлән, «Зөлхәбирә» бәете мондый юллардан башлана:

Әрбагый итеп чыгардылар

---

[8] *Макаров Г.М.* Татарстанның Биек Тау районы Сая һәм Әбрә авылларында 1988 елның сентябрь аенда үткәрелгән фольклор-этнографик экспедиция материаллары.

*Макаров Г.М.* Татарстанның Балык Бистәсе районы Күгәрчен авылында 1995 елның июнь-июль айларында үткәрелгән фольклор-этнографик экспедиция материаллары.

Кичү илләренең имамын...

Бүгенге көндә музыкаль-шигъри әрбагыйга игътибар арта бара. Аның сәбәбе, беренчедән, татар халкының Урта гасыр классик мәдәнияте белән бәет-мөнәҗәт сәнгате эчтәлегенең сыйфатларын киңәйтү ресурслары зур булганнан һәм, икенчедән, совет чоры татар фольклор белеме оешу дәверендә әлеге жанрны хаксыз һәм ясалма рәвештә фәннитикшеренү аппаратыннан төшереп калдыру күренеше белән дә бәйле. Чыннан да, үзенең хосусый сыйфатлары булса да, «робагый» төшенчәсе татар фольклор атамаларының фәнниклассификацион системасына кертелмәде.

## Касыйдә

Язма традицияләргә нигезләнгән бу музыкаль-поэтик жанр татар мәдәниятендә һәм халык көнкүрешендә әле дә сакланып килә. Идел-Урал төбәкләрендә үткәрелгән музыкаль-этнографик экспедицияләр барышында шул ачыкланды: иляһи шигърият белән бәйле күп кенә әсәрләрне халыкта һаман да «касыйдә» дип йөртү күренеше дәвам итә. Һичшиксез, бу атама гади халык мәдәниятенә классик язма шигърият аша кергән[9]. Касыйдә нигезен бәетләр (икеюллыклар) тәшкил иткән. Аларның рифмалары а а, б а, в а... принцибы буенча төзелгән. Касыйдәләр, классик шигырь формасы буларак, гаруз вәзеннәренең берсенә нигезләнеп язылганнар.

Урта гасырларның соңгы дәверендәге татар шигъриятендә касыйдә жанры актив кулланылган. Мәсәлән, шагыйрь, җырчы-хафиз, мәкам остазы Вәлид Каргалый (XVIII йөз–1803)[10] касыйдәләре. Урта гасырларның классик дәверендә касыйдәләр сарай шагыйрьләре тарафыннан ханнарга, җиңүче гаскәр башлыкларына, яисә Мөхәммәт пәйгамбәргә,

[9] Әдәбият белеме сүзлеге. Төзүче-редактор А.Г. Әхмәдуллин. Казан, Татарстан китап нәшрияты, 1990. 63, 64 б., касыйдә.

[10] *Вәлид Каргалый.* Татар поэзиясе анталогиясе. I китап. – Казан, 1992. 218, 219 б.

ислам тарихы белән бәйле башка күренекле шәхесләргә багышлап язылганнар.

## Газәл

Бу термин белән татар халкы яшәгән кайбер төбәкләрдә мәгънәсе ягыннан бәет һәм мөнәҗәткә якын булган шигъри-музыкаль әсәрләрләрне атыйлар. Классик шигърияттә исә лирик бүлемгә кергән бу шигырь формасы өч бәеттән (икеюллыктан) ким булмаган, әмма унике бәеттән артмаган. Кагыйдә буларак, газәлләрнең төп эчтәлегендә хатын-кызга багышланган гыйшык уты яисә бәхетсез, җавапсыз мәхәббәт турындагы моңлану хисләре чагылган.

Урта гасырларның соңгы дәверендә иҗат иткән татар шагыйрьләренең иҗади мирасында газәл формасында язылган һәм заманында танбур, дәф, нәй кебек классик шәрык уен коралларына кушылып башкарылган, мәхәббәт темасына багышланган шигырьләрнең үрнәкләре сакланган. Югарыда телгә алынган фольклор материалларына таянып, шуны әйтергә мөмкин, татарларда кулланылган газәл мәкамнәренең көй рәсемнәре, икагъ-ритм сыйфатлары гадәти китаби көйләргә охшаш булганнар.

Гомуми рәвештә караганда, газәл жанрының үзенчәлекләре Мәүла Колый (XVII йөзнең икенче яртысы)[11], Сайяди (XVII йөз)[12], Г. Кандалый (1797–1860) кебек татар шагыйрьләре иҗатында чагылган.

## Иляһи

Бу атаманың төп мәгънәсе «иляһият рухлы шигырь». Ул татар халкының вокаль-поэтик иҗатындагы бик үзенчәлекле, әмма хәзер инде актив кулланыштан төшкән жанр бүлеме төшенчәсен тәшкил итә. «Иляһи» төшенчәсе сыйфатының үзенчәлеге шунда: аның белән дини-рухани

[11] Татар поэзиясе антологиясе. I китап. – Казан, 1992. 179–187 б.

[12] Шунда ук. 171–175 б.

(иляһи) эчтәлекле музыкаль-шигъри әсәрләрне атаганнар. Шуңа күрә «иляһи шигърият», «иляһи музыка» төшенчәләре беренче нәүбәттә әсәрләрнең тышкы шәкелен (формасын) түгел, конкрет әсәрнең рухи эчтәлек юнәлешен чагылдыра.

Махсус фәнни музыкаль-тикшеренү әдәбиятында ислами халыклардагы «иляһи» атамалы жанрдагы музыкаль-шигъри әсәрләр турында мәгълүматлар әлегә кадәр аз. Фәкать төрек музыкасына багышланган чыганакларда гына бу жанрдагы әсәрләр хакында һәм аларның бүгенге көнгә кадәр популяр сәнгать булуы турында төрле характердагы мәгълүмат табып була.

## Зекер (зикер, әзкар)

Зекер жанры татар халкының ислам белән бәйле традицион музыкаль-шигъри сәнгатенә мөнәсәбәте булган, әмма фәндә аз өйрәнелеп тасвирланган күренешкә керә.

«Зекер» атамасының мәгънәләре берничә төрле. Безнең темага бәйле булганнары түбәндәгечә: а) Аллаһыны, аның исемен яд итү, искә алу; б) гыйбадәт кылучының, Аллаһыны истән чыгармыйча бертуктаусыз дога кылуы; в) зекер кылуның махсус тәртибе һәм аңа бәйле йолалар җыелмасы[13].

Зекер итү күренеше суфыйлар мәрасимнәрендә аеруча зур урын биләгән. Чөнки зекер суфыйчылык юлы терәкләренең берсе санала һәм даими тәртиптә зекер итү шул юлдагы юлчының Аллаһыга якынлашу торышына, ягъни *истигъракка* керә алу сәләте белән бәйле. Ул торыш мөритләрнең (эзләүчеләрнең) махсус рухи тәэссорат ысуллары аркылы, Аллаһы исемен (исемнәрен) зекер итеп (искә алып, кабатлап), Аллаһыга якынлашуга әзерлекең бер өлешен тәшкил итә. Суфыйчылыкның төрле тарикатьләре барлыкка килеп үсеш алгач (XII йөз башы – XIV йөз), зекер шактый катлаулы мәрасим (йола) булып оеша. Аның үтәлеше, төрле юнәлешләргә бүленеп, җентекле рәвештә эшләнелгән

[13] Ислам. Энциклопедический словарь. – М.: Наука, 1991. С. 77.

кагыйдәләр белән катлаулана бара. Зекер итү өчен махсус ритмлы хәрәкәтләр башкару ысулларын, алдан билгеләнгән позаларны, ягъни *җәлсәләрне* белү, тын алу тәртибен игътибарда тотуны, ягъни *хәбесән нәфес, хәбесе дәм* тәртипләрен белү сорала. Мәсәлән, сулыш алганда яисә сулыш чыгарганда суфыйлар, хәрәкәтләрен, зиһеннәрен бер фикердә туплап, махсус, зекер гыйбарәсен күңелдән кабатлап яки тел белән әйтеп, шул зекерне, вакыты белән тын алышын тоткарлап, тәннең төрле өлешенә юнәлтү ысулын белергә тиеш булганнар.

## Хушаваз

Бу төшенчәнең татар халкының традицион мәдәниятендә ике мәгънәдә кулланылуы билгеле. Беренчесендә – ул Әстерхан төбәге татарларының шигъри-вокаль сәнгатендә жанр буларак мәгълүм; икенчесендә – Урта гасыр шигъриятендә кулланылган махсус атама буларак билгеле. «Хушаваз» төшенчәсе татар музыка белеменә М.Н. Нигъмәтҗанов хезмәтләре аша керде. Әстерхан өлкәсендә яшәүче нугай татарларының көйләп сөйләү өслүбе чагылган бу жанр галим тарафыннан 1960 елларда язып алынганча тасвирлана. Хушавазлар, автор язганча, бәетләр тематикасы кебек үк, шактый киң колачлы һәм гади көнкүрештә булганнардан алып зур тарихи вакыйгаларны да тасвирларга сәләтле. Кайбер хушавазларны башкару вакыты берничә сәгатькә сузылырга мөмкин. Күптән үткән вакыйгалардан алып, хушавазларда хәзерге көн вакыйгалары да чагылырга мөмкин. Мәсәлән, Бөек Ватан сугышы (бәетләр кебек үк), фаҗигале үлем һ.б. вакыйгалар турындагы хушавазлар. Хушавазларны көйләп әйтү, гадәттә, думбырага кушылып башкарылган[14].

Урта гасырларда үсеш алган шигъри-музыкаль жанрларның халык сәнгатенә тәэсир иткән йогынтысы турындагы сорауларны күзәтүне тәмамлап, шуны әйтергә мөмкин:

[14] *Нигмедзянов М.Н.* Татарские народные песни. – М.: «Сов. композитор», 1970. С. 184.

халыкның гади көнкүрештәге аңында классик шигърияткә хас төшенчәләр һәм атамалар, аларның мәгънә күләмнәре даими, диалектик рәвештә үзгәрә баралар. Конкрет форма аңлаткан атамалар халыкта онытылалар, алмашыналар һәм, ниһаять, гадиләштерелгән бер атама белән, мәсәлән, «бәет», «хушаваз» һ.б. төшенчәләр аркылы белдереләләр. Мондый күренешкә М. Нигъмәтҗанов та игътибар итә: «мөнәҗәтләр һәм бәетләр еш кына бер үк көйләргә башкарыла, мәгълүмат бирүчеләр кайвакытта бәетне мөнәҗәт диләр һәм киресенчә»[15]. М. Нигъмәтҗановның бу күзәтүен касыйдә, газәл һәм робагыйларга, ә Әстерхан татарлары өчен дастан, мәктүбат, хикәят жанрларына да күчереп була, чөнки иске татар классик шигъриятенә хас «традицияләрне белүче кешеләр көннән көн азрак калалар».

[15] *Нигмедзянов М. Н.* Татарские народные песни. – Казань, 1984. С. 12.

# ИЛЯҺИ БӘЕТЛӘР ҺӘМ УЕН КОРАЛЛАРЫНДА УЙНАУ

Хәзерге көндә халыкта бәет-мөнәҗәтләр уен кораллаларында уйнамыйча гына башкарыла. Тарихи чыганаклардан күренгәнчә, Урта гасырлар дәверендә шигъри әсәрләр уен кораллары озатылышында мәкам белән көйләп башкарылганнар. Татар сәнгатендә ул суфичылык белән бәйле. Шул чорда татар суфи-дәрвишләре хәрәкәте көчле булу сәбәпле, аларның инструменталь һәм шигъри-вокаль сәнгатьләре саклана әле, әмма XIX йөз урталарыннан соң тәмам сүнүгә йөз тота. Шул рәвешле, XVI йөз уртасыннан XIX йөз уртасына кадәр классик ислами дәвердәге инструменталь традицияләр авыл укымышлылары, мөгаллимнәр кебек галим-голямаларда дәвам иткән. Бигрәк тә рухи белем-тәрбияләрен Урта һәм Якын Шәрыктагы мөселман илләренең дини, мәдәни мәркәзләрендә алган ишаннарда, абызларда, аларның мөритләренең суфичылык белән бәйле гамәлиятләрендә. Мондый элемтәләр татар суфиларының уен коралларын һәм вокаль-шигъри сәнгатьләрен исламият дөньясының мәдәни-мәгълүмати кырында саклау өчен үтә әһәмиятле була. Бу чорның дини-мәдәни үсеше вазгыяте түбәндәгечә була.

XVI йөзнең уртасында Казанны яулап алу нәтиҗәсендә халык арасындагы милли-дәүләти үзәктән килә торган барлык административ, дини элемтәләр челтәре юкка чыгарыла. Татарлар үзләренең эчке дөньяларына, мөселман өммәтләренә бикләнеп, тышкы дөнья элемтәләреннән баш тартып, йомы-

лып яши башлыйлар. Тормышның барлык авырлыкларын татарлар Аллаһыдан бирелгән сынау дип кабул итәләр. Бу исә халык аңында суфичылык тәгълиматы таралуга китергән шартлар тудыра, һәм әлеге факторлар халыкның милли-мәдәни, дини үзенчәлекләрне саклауга юнәлдерелгән ныклыкка, сабырлыкка зур көч өсти.

Татар халкының күпчелеге эчке дөньяларына бикләнү күренеше – ул кеше хокукын бозу, җәбер-золымга каршы юнәлдерелгән һәм эндәшмичә белдергән эчке протест билгесе була. Мондый гамәл, әлбәттә, халыкны Урта гасырларга хас рухи кыйммәтләргә өстенлек бирүгә китерә. Татарларда ул дәвердә нәкышбәндия тарикатенә хас фәлсәфи карашлар зур роль уйный. Русиянең сәяси, социаль, дини кысулары чынбарлыгында күрсәтелгән процесслар халыкның үз-үзен саклау эшендә табигый чаралар ролен башкара.

Шуңа күрә халык ислам дөньясына, Урта Азиянең дини, мәдәни-мәгълүмати сферасына якынрак булырга тырыша. Шуңа күрә татар яшьләре белем алыр өчен Бохара, Сәмәрканд, Кабул, Кандаһар шәһәрләренә кадәр барган. Бу үзәкләрдән туктаусыз агым булып дини-фәлсәфи әдәбият, дөньяви һәм иляһи сәнгать әсәрләре килә. Бу иске классик дәвердән, Казан ханлыгы мәдәниятенең дәвамы буларак килгән шигъри-музыкаль, уен коралларында башкару сәнгате кебек күренешләрнең тотрыклыгын ныгыта.

Билгеле ки, Идел һәм Урал буйларында таралыш тапкан суфичылыкның музыкаль традицияләре бик оригиналь, әмма алар, һәм, гомумән, татар халкының иляһи сәнгате тарихы аз өйрәнелгән күренеш булып кала.

Классик ислам официаль рәвештә музыка, театр, бию сәнгатен турыдан-туры кире какмый, әмма еш кына аны тулысы белән, искәрмәсез кабул итүне дә хуп күрми. Аерым ислам белгечләре музыканы тәнкыйтьләп, аны гөнаһ чыганагы итеп күрсәтергә дә мөмкиннәр. Ләкин, музыка, сәнгатьнең башка төрләре кебек үк, беренчел нейтраль һәм

абстракт мәгънәдәге нәфис тасвири чаралар ярдәмендә иҗат ителә. Шул бер үк нәфислек чараларын конкрет эчтәлекле теләкләргә ирештерү өчен, ягъни изгелекле, яисә гөнаһлы, пычрак максатларда да кулланып була. Аларны сайлау исә иҗат кешеләренең рухи тәрбиясе белән турыдан бәйле.

Классик исламдагы дини сәнгать үсешендә музыка сәнгатеннән тыю күренешләре шактый уңышлы рәвештә суфичылыкта компенсацияләнә. Үзенең барлыкка килү вакытыннан ук суфичылык тирән фәлсәфәле, рухи эзләнүләргә юнәлгән тәгълимат буларак танылa. Татар суфилары да классик ислами сәнгать һәм Идел-Урал төбәгенең борынгы этник сәнгате элементларын куллануны мәгъкүл күргәннәр[16].

Дәрвишлек тормышын аңлы рәвештә сайлаган татар суфилары бергә җыелып, гади авыл өе, алачык, яисә ярымземлянка рәвешендәге махсус төзелгән Ханәкәләрдә яшәгәннәр. Мондый ханәкәләр авыллардан читкәрәк, кайвакытта *әүлия* булып танылган күренкле суфилар күмелгән дөрбәләр, мазарлар тирәсендә дә төзелгән. Урта гасырларда һәм аның соңгы дәверендә яшәгән дәрвишләрнең һәм аларның Ханәкәләре төзелгән урыннар турындагы мәгълүматлар әдәбиятта аз түгел[17].

XIX йөз ахыры – XX йөз башындагы татар суфиларын тасвирлаган берничә мисал китерәбез. Язучы һәм журналист Зариф Мозаффари, үз күзләре белән күргәннәрне совет идеологиясенең тәнкыйди күзлегеннән карап, суфиларны түбәндәгечә итеп тасвирлый: «нәкышбәнди ишаннарының өсләрендә чигелгән чикмәннәре, шул ук рәвешле чигеп ясалган бүрекләре була. Болар шул чапан-бүрекләрен киеп, базарларда «Аллаһу»лап йөргәннәр. Нәкышбәндиләр зикерне яшерен әйткән булсалар, бу ишаннар, сәдака алыр өченмедер, базарларда кычкырып зикер әйтәләр». Ул шундый ишаннарның кайберләрен искә дә ала. Мәсәлән, Эстәрлебашы Харис һәм Хәррас ишаннар – Нигъмәтулла ишан балаларыдыр; Корыч ишан – элеккеге

[16] Кара: Ат-Тасаввуф (суфизм) // Ислам. Энциклопедический словарь. М., 1991. С. 225.
[17] Мөслими Тәварихы Болгария (Болгар тарихы). – Казан, 1999.

Бәләбәй кантуны Корыч волосте Бэдретдин ишан; Муса ишан Рәсүлев; Каргалы һәм Ялпактал ишаннары; Эстәрлетамак Камал ишан; Чиләбе Аксак ишан, Ишми ишан һ.б.[18]

Журналист һәм педагог Вафа Бәхтияров Камчылы ишанның өендә суфиларның зикер әйтүләрен түбәндәгечә тасвирлый: «Казанның Камчылы ишаны Фатих Әмирханнар өенә каршы гына тора иде. Фатих Әмирханга барганда, Тукай Камчылы ишанның мәчеттән чыгып килгәнен берничә тапкыр күрде. Моннан башка тагын 1907 елның ахырында, җомга көнгә каршы кич белән, Фатихларда булдык. Бераз утыргач, кайтырга чыктык. Без чыкканда, капка төбендә байтак җигүле атлар тора иде. Башта, бу хәлне күргәч, без туй мәҗлесе булырга кирәк дип уйладык. Сораштыргач, Камчылы ишанның мөридләре белән гыйбадәт мәҗлесе икәнен белдек. Без дә кереп карарга булдык. Без кергәндә, өйнең залында мөридләр түгәрәкләнеп утырганнар. Түгәрәк уртасында зур чалма кигән Камчылы ишан утыра. Шау килеп: «Яһу, яһу... яһу...» – дип кычкырып тавышлап утыралар иде. Берничәсе сикереп торып, шул түгәрәк эчендә сикереп, кычкырып, йөри башладылар. Бу күренеш Тукайны шомландырды булса кирәк: «Әйдә чыгабыз», – диде, без чыгып киттек»[19]. Күренгәнчә, монда Казан суфиларының зикер әйтү гамәленә хас бер күренеш тасвирланган. Бу тасвирлама шунысы белән дә гыйбрәтле: XX гасыр башында яшь татар зыялылары (шул исәптән Г. Тукай да) суфичылыкны кабул итмәгәннәр, аңа тәнкыйть күзлегеннән караганнар, аның дөньяви һәм дини эчтәлекле сәнгать юнәлешләрен принципиаль рәвештә татар милләтенең яңа дәвер мәдәниятенә турыдан-туры кертмәгәннәр, аларны аерым яссылыкка куеп, аерып караганнар. Идел буендагы ислам мәдәниятенең инде меңьеллык тарихлы тамыры булганлыгын белү дә моңа комачау итә алмаган.

---

[18] *Мозаффары Зариф.* Ишаннар-дәрвишләр. – Казан: Татиздат, 1931. 25–66 б.

[19] Тукай турында истәлекләр. – Казан, 1986. 82 б.

Татар дәрвишләренең көнкүрешләре турында мәгълүматлар бик аз, чөнки алар яшерен, йомык тормыш рәвеше алып барганнар.

Әлбәттә, Урта гасырларның соңгы дәверенә хас татар музыка мәдәниятен өйрәнүдә Габдерәхим Утыз-Имәни әл-Болгари (1756–1834), Таҗетдин Ялчыгол әл-Болгари (1768–1838), Габделҗаббар Кандалый (1797–1860), Шиһабетдин Мәрҗани (1818–1889), Каюм Насыйри (1825–1902) кебек күренекле мәгърифәтчеләр һәм галимнәр иҗат иткән әсәрләр зур урын алып тора. Алар хезмәтләрендә үз дәверләрендәге татар җәмгыятендә барган процессларның үзенчәлекләрен чагылдырганнар. Әлеге галимнәрнең язмаларында бу чор татар җәмгыятенең тирән кризис кичерүен, татар тормышының дини һәм дөньяви өлкәләрендә реформалар (ислах) кирәклеге, җиңел булмаган яңа юллар эзләүләр чагыла.

Аларның иҗатында без Урта гасыр татар җәмгыятендә, ягъни Идел буе җирле төркиләрнең музыкаль эстетикасында классик ислами музыкаль мәдәниятенең гамәлияте һәм теориясен кабул итү үзенчәлекләренең чагылуын, ул традицияләрнең адаптацияләнү нәтиҗәләрен күрә алабыз. Алар иҗатында XVIII–XIX йөздәге татар музыкаль көнкүреше тасвирлана, анда күренекле мәкамчеләр, хафизлар, музыка коралларында башкаручылар турындагы язмалар бар. Бу мәгълүматлар кыйммәтле беренчел чыганаклар булып тора.

Югарыда без Урта гасырнын соңгы дәверендә, XVIII–XIX йөзләрдәге татар уен кораллары сәнгатенең тәмамланышына хас һәм безгә билгеле булган мәгълүматларның, чишелешен көткән мәсьәләләрнең гомуми манзарасын китердек. Алар күрсәтүенчә, бу процесс үтә катлаулы тарихи үсеш юлын тәшкил итә. Моннан бик мөһим нәтиҗә ясарга мөмкин: XVIII–XIX йөзләрдәге татар уен кораллары сәнгатен гади этник һәм көнкүрештәге фольклор сәнгатенең тар кысаларында гына өйрәнү мөмкин түгел. Монда ачык ки, бу дәвердәге татар музыкасы классик шәрык сәнгате күренешләре белән ту-

рыдан бәйле, аның башлангычлары татарларның Урта гасыр элитар мәдәниятенә барып тоташа.

Урта гасырларның соңгы дәверендәге татар суфилары арасында төрле уен коралларында башкару осталыгы белән ишан Җәгъфәр әс-Сафари таныла. Җәгъфәр ишан Идел буендагы ислам дине һәм ислам сәнгате үсеше тарихында билгеле шәхесләр исемлегенә керә. Аның турында Таҗетдин Ялчыгол, Шиһабетдин Мәрҗани[20], Ризаэддин Фәхреддин һәм башка галимнәр яздылар. Татар музыкасы тарихында ул суфичылык катламын һәм өслүбен тәшкил иткән юнәлеш вәкиле буларак мәгълүм. Җәгъфәр ишан үтә зур осталык белән хөрәсән танбурында (төрки танбурда) уйнаган һәм үзенең сәнгатенә мөридләрен дә өйрәткән. Риваятьләрдән күренгәнчә, ул төрле уен коралларында уйнап, касыйдә, газәлләр көйләп, суфи зикерләрен оештырган.

Җәгъфәр ишанны һәм аның мөридләрен еш кына төрле дини бәйрәмнәр уздыру мәҗлесләренә чакырганнар. Алар мондый мәҗлесләрдә нечкә зәвык белән суфичыл эчтәлекле музыкаль-шигъри әсәрләр башкарганнар. Аларны, күпчелектә, яхшы тормышлы байлар яисә Идел һәм Урал арасындагы төрле авылларның аерым мөселман җыеннары үзләренә чакырган.

Җәгъфәр ишанның тулы исеме – Җәгъфәр бине Габид бине Исхак бине КотлыгМөхәммәт бине Нариман әс-Сафари. Ул Уфа губернасының Чишмә волостенә караган Сафар авылында туган (хәзерге Башкортстан, Чишмә районы, Сафар авылы)[21]. Бик яшьли ятим кала. Аның анасы Рәҗәб Сафар авылы мулласы Хәлил бине Асылхуҗа бине Әмирхан бине Шәриф кызы була. Ире вафат булгач, ул Арыслан авылы мулласына кияүгә

---

[20] *Мәрҗани Ш.* Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. Китапны тәрҗемә итүче һәм төзүче Хәйруллин Ә.Н. – Казан: Тат. кит. нәшр., 1989. – 278 б.

[21] *Макаров Г.М.* Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты тарафыннан Башкортостанның Чишмә районына оештырылган фольклор-этнографик экспедиция материаллары (1.07–10.07. 1994 ел).

чыга. Җәгъфәрнең балачагы Арыслан авылында үтә (әлеге авылның кешеләре үзләренең этник чыгышлары буенча мишәр татарлары кавеменнән булалар). Авыл мәдрәсәсен тәмамлагач, ул Бохарага укырга китә. Белемен камилләштерү өчен, Кабулга юл ала. Анда ул күренекле дин белгече, галим буларак шөһрәт казанган ишан Фәезхан Хазырхан әл-Кабулинең мөриде була. Дин белеменең югары баскычларына күтәрелеп, югары рухи камилият дәрәҗәләрен үзләштерә алгач, Җәгъфәр әс-Сафари үзенең рухи укытучысыннан язма рәвешле иршаднамә ала һәм, мөстәкыйль рәвештә үзе ишан булып, мөселманнарга белем нуры һәм рухи тәрбия бирү өчен фатиха ала.

Туган якларына кайтса да, аны монда көтеп торучы булмый. Чөнки аңа яшәр өчен җир бүлеп бирүгә кирәк булган рәсми кәгазләр атасының төп чыгышы теркәлү урыны белән бәйле була. Шулай итеп Җәгъфәр ишан бабалары яшәгән төп җирлеккә – Иске Тимошкин авылына (хәзерге Башкортостанның Авыргазы районы) китә. Ул монда суфичылык хәрәкәтендә бик актив катнаша һәм ишан булып үзенә мөридләр туплый, ханәкә сала. Аның рухи мәзһәбе нәкышбәндия тәгълиматенә нигезләнә. Тикшеренүчеләр билгеләгәнчә, Җәгъфәр ишан даими рәвештә юлда йөри, суфичылык тәгълиматын өндәп ерак сәфәрләргә чыга торган булган. Җәгъфәр ишан, олыгаеп, 1831 елда вафат була һәм авыл зиратына дәфен кылына.

Җәгъфәр ишан үзенең музыкаль-теоретик белемнәрен, төрле уен коралларында уйнау осталыгын Бохарада һәм Кабулда яшәгәндә ныгыткандыр. Чөнки анда суфиларның төрле дини-гыйбадәт мәҗлесләрендә музыка һәм шигърият сәнгатен куллану гамәлияте киң таралган күренеш булган. Табигый ки, болар барысы да аңа классик ислам сәнгатенең эстетикасын һәм теориясен яхшырак үзләштерергә мөмкинлек биргән.

Җәгъфәр ишанның тормышы һәм иҗаты мисалында шуларны күреп була: татар җәмгыятендәге дини сәнгать вәкилләренең Урта Азия суфиларына хас музыка һәм шигъ-

ри сәнгатләре белән аралашуны өзмәү Урта Идел буенда татарларга классик ислами уен кораллары сәнгатен саклап калу мөмкинлеген биргән, Казан ханлыгы дәвереннән килгән традицияләрне өзеп бетермәскә җирлек булган.

Җәгъфәр ишан еш кына тирә-яктагы дәрвиш Ханәкәләренә барган һәм андагы суфилар белән очрашкан. Билгеле ки, ишан күп тапкыр Болгар, Биләр, шулай ук Бәләбәй өязе Сафар авылы тирәләрендәге мөселман әүлияләренең дөрбәләренә зиярәт кыла торган була. Ул шулай ук хәзерге Татарстанның Балтач районы Оры авылында яшәгән Хәбибулла ишан белән элемтәдә тора, Ирнә суы буена урнашкан Мәлем авылында һәм башка урыннарда да була. Җәгъфәр ишанның кешеләрне төрле авырулардан имләү сәләте дә бик югары бәяләнә.

Музыка кораллары турында кыйммәтле мәгълүматлар Г. Утыз Имәни әсәрләрендә дә бар. Аның «Гуариф-эз-заман» исемле поэмасыннан Зәй, Шушма, Чирмешән елгалары тирәлегендә урнашкан мөселман авылларында хәтта махсус бербөтен ансамбльләр кулланылганын да күреп була[22]:

Кубыз, танбур вә нәй, гайре уенлар
Килер уртага кыз вә җәваннар.
Бу рәсвалык белән та сөбхе садикъ,
Идәрләр эш шәятинга муафикъ.

Югарыда телгә алынган авторларның әсәрләреннән шул күренә: әлеге вакыткача мөселман өммәте мохитендә яшәгән һәм аңа тугъры калган татар яшьләре кубыз, танбур, нәй, дәф кебек уен коралларында уйнап күңел ачканнар, чөнки аларны татар халкы үзенең иң авыр сынау көннәрендә дә, ягъни XVI йөз уртасыннан алып XIX йөз урталарына кадәр саклап кала алган. Бу гаҗәп хәл булып кабул ителә, чөнки әлеге гомумислами элитар классик уен коралары авыл мохитендә саклана алмас кебек иде. Моны ничек аңлап һәм аңлатып була соң?

[22] *Утыз-Имәни Габдерәхим.* Шигырьләр, поэмалар (Төз. Ә. Шәрипов). – Казан: Тат. кит. нәшр., 1985. 32–35 б.

Урта гасырларның соңгы дәверендә татар халкы яшәгән авыллардагы муллалар, абызлар үзләренең тәртип, иман һәм йола тамырлыкларын саклау эшендә үтә кырыс булганнар, дөньяви сәнгатькә катгый рәвештә каршы торганнар. Алар хәтта могҗиза рәвешендә сакланып калган үзебезнең иске төрки-татар уен коралларын да «гөнаһ» һәм «бидгать» дип игълан иткәннәр. Чөнки рухи яктан исән калу, саклану механизмнары үтә көчле булган.

Күренекле дин галиме, тарихчы, мәгърифәтче Таҗеддин Ялчыголның иҗади мирасы шул чордагы татар тормышына нисбәтле күп мәгълүматны үз эченә ала. Аның хезмәтләре татар халкының Урта гасырларның соңгы дәверенә караган ислами классик уен кораллары сәнгатен өйрәнү өчен беренчел чыганак булулыгы белән дә кыйммәтле. Инструменталь музыка сәнгатенә караган материаллар аның безгә билгеле булган ике хезмәтендә чагыла. «Рисаләи Газизә» (1796) әсәре аның Суфи Аллаһияр (1630–1723) тарафыннан язылган «Сөбател гаҗизин» («Көчсезләрнең ныклыгы») китабының тәфсирен тәшкил итә. Т. Ялчыгол анда Шәһри Болгар каласы хәрабәләре буенда балчыктан ханәкәләр төзеп яшәгән суфи-дәрвишләрне тасвирлый һәм аларның төрле музыка коралларын, шул исәптән танбур һәм гөслә кулланганнары турында яза.

Кадими заман музыкаль-шигъри әсәрләрдәге классик вәзен (метр) һәм икагъ (ритм) үзенчәлекләрен ачык чагылдырып башкару өчен төп уен коралы вазифаларын *дәф* исемле бәрмәле уен коралы башкара.

Татар халкының Урта гасырлар инструменталь сәнгатендә дәф уен коралында башкару традицияләре Идел буеның ислам цивилизациясе мохитенә керү белән башланып китә, әмма яңа вакыт дәверендәге милли сәнгатьтә дәфтә башкару традицияләре, алымнары югала һәм бу уен коралы онытылуга дучар ителә.

Урта гасырларда формалашкан язма әдәбият белән бәйле иске татар классик музыка мәдәниятендә, шул исәптән күрсәтелгән чордагы вокаль һәм инструменталь сәнгатендә,

дәфтә уйнау традицияләре булганлыгы турындагы фикер иртәме-соңмы барыбер дөньяга чыгар иде. Мондый фикер табигый, чөнки ул Урта гасыр татар элитар мәдәнияте үсешенә хас күренеш. Билгеле ки, бу уен коралының репертуарын, башкару алымнарын ретроспекцияле анализ аша тергезү проблемасы бүгенге көн тәртибенә куелуы гаҗәп түгел.

Әйтергә кирәк, язма шигърият белән аерылгысыз булган иске татар вокаль сәнгатенә хас иляһи һәм дөньяви әсәрләрнең башкару өслүбен табу һәм тергезү, шактый зур өлешендә нәкъ менә дәфтә башкарылган өсүл алымнарын кайтару белән бәйле. Дәфне әлеге өслүб катламына керә алуның «ачкычы» дип тә була.

Мәкам белән көйләп уку гыйлеме нигезләрен үзләштермәгән кайбер башкаручылар бәет-мөнәҗәтләрне авыл көйләре өслүбе кануннарына буйсындырып башкаралар. Димәк, бүгенге көндә мәдәни мирасыбызның өслүб үзенчәлекләрен бутап бетермичә, өслүб тазалыгын саклап калу мөһим бурыч булып кала. Шуңа күрә әлеге җыентыкны басмага әзерләү барышында дәф коралы кулланылды.

Көйләп уку сәнгатен тергезү, фәнни тикшеренүләргә һәм эзләнүләргә таянып, вокаль һәм инструменталь башкаручылык традицияләрен бүгенге көндәге сәнгать гамәленә кертү. Аның өчен көйләп уку феноменының шигъри һәм музыкаль текстологик үзенчәлекләрен белү, вокаль һәм инструменталь башкарылу хосусиятләрен өйрәнү кирәк. Бу сәнгать төренең татар мәдәниятендә барлыкка килү алшартларын, нигезендәге төп чыганакларын ачыклау, тарихи үсеш язмышларын тикшерү, перспектив үсеш мөмкинлекләрен күзаллый белү таләп ителә. Бу очракта көйләп уку сәнгатен гамәли тергезү мөмкинлекләре бермә-бер артачак.

*Геннадий Михайлович Макаров,*
*сәнгать фәннәре кандидаты, Казан консерваториясенең*
*этномузыкология кафедрасы доценты*

# РУХИ МИРАСЫБЫЗ ЯДКАРЬЛӘРЕ

## КОЛ ШӘРИФ

Хаҗитархан ханлыгында (хәзерге Әстерхан шәһәре) XVI гасыр башында Мансур сәет гаиләсендә туа. Башлангыч белемне әтисеннән ала. Казанның җәмигъ мәчете имамы, мәдрәсә-и галия мөдәррисе, «судат-гызам» (садати-гозам) – дәүләтнең иң мәртәбәле дин башлыгы (бөек сәид) итеп таныла (1546 яки 1551 елдан соң). Ханнар алышынган вакытта, ханлыкның вакытлы хөкүмәтләрен җитәкли. Казаннан Зөя каласына җибәрелгән илчелек җитәкчесе (1551). Ядегәр Мөхәммәд хан хөкүмәте әгъзасы. Галим, мәгърифәтче, шагыйрь, дипломат һәм дәүләт эшлеклесе. Казанны саклаучыларның соңгылары рәтендә, үзенең бер төркем шәкертләре белән шәһид китә.

Башың күтәр гафләтдин, гафил торма, һу тигел,
Күзең ачкыл уйкудин, гафил торма, һу тигел.
Һу-һу тийү һу кошы, акар күзендин йәше,
Көйеп эче һәм тышы, гафил торма, һу тигел.
Гашыйклары очарлар, гарше шахига кунарлар,
Һу дип дидар куларлар, гафил торма, һу тигел.
Йите әкълим гизәрләр, андин күккә агарлар,
Бер кадәмдә нитәрләр, гафил торма, һу тигел.
Һу бәхригә чумарлар, гаувас булып батарлар,

Һу дөррләрин тирәрләр, гафил йөрмә, һу тигел.
Дәргяһ капуг очыкдыр, рәхмәтләри анукдыр,
Күзең ачып бакып тор, гафил йөрмә, һу тигел.
И Кол Шәриф, тынмагыл, төнләр йатып оймагыл,
Хак зекрени куймагыл, гафил йөрмә, һу тигел.

***Тәрҗемә:***

Башың күтәр ваемсызлыктан, белми торма, «Аллаһу» диген,
Күзең ач син йокыдан, белми торма, «Аллаһу» диген.
«Һу-һу» дияр һу кошы,[23] агар күзеннән яше,
Көеп эче һәм тышы, белми торма, «Аллаһу» диген.
Гашыйк булганнар очарлар, гарше шахига[24] кунарлар,
«Аллаһу» дип очрашу көтәрләр, белми торма, «Аллаһу» диген.
Җиде климат гизәрләр, аннан күккә ашарлар,
Бер атлауда җитәрләр, белми торма, «Аллаһу» диген.
«Аллаһу» диңгезенә чумарлар, су асты йөзүчесе булып[25] батарлар,
«Аллаһу» энҗеләрен эзләрләр, белми торма, «Аллаһу» диген.
Оҗмах ишеге ачыктыр, рәхмәтләре билгеледер,
Күзең ачып карап тор, белми йөрмә, «Аллаһу» диген.
И Кол Шәриф, тынма син, төннәрен ятып йоклама,
Аллаһка зикер әйтүне ташлама, белми йөрмә, «Аллаһу» диген.

* * *

Әлхәмдүлиллаһ раббил-галәмин, шөкер сәңа,
Үзең кабул бирдең иман безгә. [...]
Безне кыйлды Мостафаның өммәтендин,
Йибәрде Мостафаны борһан безгә. [...]
Кем котылгай Рәсүледин Гыйнаятьсез?
Аның күңле арар булса Шәфәгатьсез, – [...]
«Лям тәкулүнә ма-ля тәфгалүн» айәтендә
Тәфсир кыйлмыш ул кыямәт атлыйгъ көндә;

[23] Һу кошы – оҗмах кошы, Аллаһка бирелгән кеше.

[24] Гарше шахи – күкнең иң югары тугызынчы катында урнашкан Аллаһ тәхетен тотып торучы агач ботагы.

[25] Гауuас – суга бик оста чумучы.

Үзе укыб, үзе тотмас данишмәндкә,
Ирекләндерер өч йөз алтмыш бәла безгә. [...]
Укыб-белеп тотмадык без хитабындин, –
«Йа-вәйләти ләййәтәни» дәрман безгә.
Үзең бел гел, йангыл имди, и Кол Шәриф,
Тәхсил тийү бар гомерең кыйлдың тәләф.
Йекетлектә тәүбә кыйлмак – гыйнаятьь ризык,
Йазыкларны йарлыкали гофран безгә.

***Тәрҗемәсе:***
Аллага, Галәмнең хуҗасына, дан булсын, шөкер сиңа!
Үзең кабул бирдең иман безгә, [...]
Безне Мөхәммәт пәйгамбәр өммәтеннән яратты ул,
Мөхәммәт пәйгамбәрне дәлил итеп безгә җибәрде ул. [...]
Кем котыла алсын ярдәмчесез,
Мөхәммәт пәйгамбәр ярдәменнән башка? [...]
«Үзе эшләмәгән гамәлләрдән ничек халыкка нәсыйхәт бирер» аятьендә
Аңлатып бирде Ул: «кыямәт» дип аталган көндә,
Үзе әйтеп тә, шул гамәлләрне үзе тотмаган галимгә,
Әйтеп торыр өч йөз алтмыш бәла безгә. [...]
Без укыдык-белдек, әмма тотмадык Аллаһ нәсыйхәтеннән, –
«Ни үкенеч! Әй, булса иде!». сүзләре генә юаныч безгә.
Үзең бел дә ян инде, и Кол Шәриф,
«Белем алам» дип, бөтен гомереңне үткәреп бетердең.
Егет чакта тәүбә итү Аллаһның ярдәме (ризыгы) кебек ул,
Гөнаһларны ярлыка инде, Аллаһ, безнең.

* * *

[...] Үзиндә булур иран йыкган, күрәр нуры Аллаһыны,
Фида булур максуд-морад, рахте гыйшрәт кызыл җандин.
Нәфәси җиһад кыйлса, күзләрендин кан-йәш акса,
Раббе тийү аңа бакса, кәлүр ләббәйкә йөз-мең йандин.
Морад кәрәк ирсә сәңа, хакыйкыйә йангыл аңа,

Гамәл кыйлып төндин-теңә, чыкмагунчә бәһ бундин.
Рийазәтнең бутасында сыз гаурәтин, и Кол Шәриф,
Кәнҗе гыйшкы кәрәк ирсә, алтун-көмүш чыка кандин.

***Тәрҗемәсе:***

[...] Үзендә ирлек һиммәте[26] булган кеше Алланың нурын күрер,
Дөньяви максат-морадларын корбан итәр ул (шул юлда), рәхәт тормышы китәр җаннан.
Әгәр нәфсесе белән сугышса, күзләреннән кан-яшь акса,
Раббем, диеп, аңа бакса, килер ләббәйкә[27] йөз-мең яктан.
Морад кирәк булса сиңа, хакыйкатьтә ян син аңа,
Гамәл кыйлып төннән төнгәчә, яхшылыктан (үзеңне камилләштерүдән) читкә чыкмыйча.
Риязәт[28] билбавындагы оят җирне[29] сызып ташла, и Кол Шәриф,
Алла гыйшкы хәзинәсе кирәк булса, алтын-көмеш каян чыгар башкача?

---

[26] Һиммәт – теләккә омтылу, тырышлык.
[27] Ләббәйкә – биредә: хуплау сүзе.
[28] Риязәт – теләкләрне тыеп тору, ашау һәм эчүдә чикләнгәнлек
[29] Оят җирне – биредә: гафләтне, битарафлыкны

# МӨХӘММӘДЬЯР

Казан ханлыгында Мәхмүд хаҗи гаиләсендә туа. Иранда илче, Казан кирмәнендә Мөхәммәдәмин хан төрбәсен караучы-мөҗавир (1541). Шагыйрь, тарихчы, дипломат, тылмач. Муромда тоткынлыкка алына һәм үтерелә (1549) (Кайбер чыганаклар буенча Иван IV гаскәрләре тарафыннан Казан камалышы барышында һәлак була (1552).

## Игелекле булсын кеше

[…] Акыллы шул – Хакка хезмәт иткәне,
Биргән нигъмәтенә шөкер иткәне.
Бар шундый: ашамас, ашатмас, диләр,
Үзе белән гүргәме илтер? диләр.
Кешелекле булсын кеше дигәнең,
Игелекле – галим, гади дигәнең.
Файда китер һәркемгә син, яңгыр күк,
Йә диңгезнең төбендәге җәүһәр күк. […]
Намуссызга хөрмәт итмәс гакълы бар:
«Асрама эт баласын – аслына тартар».
[…] Шулай булыр кем нәсихәт алмаса,
Олылар сүзен колакка салмаса».
[…] Һәркем итә икән үгет – сал колак,
Нәсихәт алмаганның эшенә бак.
Олыларның сүзе безгә – хикмәттер,
Һәркемгә дә нәсихәт – хуш, кыйммәттер.

# Нәсыйхәт

[…] Әгәр сәндә булурсә фәһме кямил,
Гөли сач ул багыңа, булма җаһил.
Багың эче булур ахир гөлстан,
Сәңа бу дидүкем бел: ула дәстан. […]
Күни бул, тугры йулә сал үзеңни,
Ерак тоткыл на-мәхрәмдин күзеңни. […]
Ирүр кямил сәнең гәңлың, гәзизем,
Хәдис, Коръән сүзен дот, и тәмизем.
Әгәр кылмасә бу сәңа сәрайәт,
Ахир бер көн килур сән күб нәдамәт
[…]Әгәр камил булсаң акыл ягына,
Надан булма, гөлләр утырт багыңа.
Бакчаң эче ахыр гөл белән тулыр,
Сиңа бу әйткәнем киная булыр. […]
Тугры юлга сал, – дөрес бул, – үзеңне,
Чит-ятлардан еракта тот күзеңне. […]
Синең акылың камил, хөрмәтле ишем,
Коръән, хәдис сүзләрен тот, саф кешем
Бу сиңа тәэсир итмәсә, белеп тор,
Ахырда күп үкенерсең, күреп тор.

# СУФИ АЛЛАҺИЯР

Сәмәрканд төбәгендәге Миңлән авылында туа (1616), ата-бабалары Идел буеннан. Бохарада укый (1626-1641), Бохара әмире тарафыннан салым җыю эшенә түрә итеп билгеләнә (1641-1667), шәех Хәбибулла мөриде, дәрвиш (1668-1670), шагыйрь. Казанда, Истамбулда була. Хаҗ сәфәре вакытында Искәндәр шәһәрендә вафат була (1713).

## Гамәлдә Аллаһыга табыну

[...] Гамәл кылу өчен йөрсәң бу юлда,
Кирәк гыйлем нуры, әлбәттә, кулда.

Караңгыда йөрсәң, юлдан язарсың,
Әгәр күзең булмаса, син азарсың.

Гаҗәеп, чөнки юлга хәтәр тулган,
Аяк куйсаң, астында кое булган.

Төзек юл дип туры атлап барырсың,
Казыкка төшкәнне toймый калырсың!

Күзең әгәр булмаса, и яхшы яр,
Аягыңны таяксыз куйма, зинһар!

Әгәр галим сүзен тотса гамәлдә,
Аны ахмак димәделәр беркем дә.

Шулдыр җаһил – шәех дип белеп үзен,
Колакка алмаса галимнең сүзен!

Диннең тамыры – «Гыйльме-гакаид»а,
Төпсез шәехкә су биреп ни файда?

Ныклы булсын синең агач тамырың,
Киемең тәкъва һәм татлы җимешең. [...]

Белеп укый белмәсә берәү «Коръән»,
Ничек тәфсирен белер шушы инсан?

Әгәр төшен алса ачык күреп ир,
Ничек күренми калды кабыгы, күр?

Дин гыйлеме чөнки өректәй, и дус,
Ләззәтледер аның төш-кабыгы, дус.

## Акыллы эшкә боеру хикәяте

[...] Укысаң, укы үз нәфсең күзенә,
Чын күз белән кара китап йөзенә.

Хаклы галим ул – әгәр гадел булса,
Күп бәхәсләр йөгертеп бәхәс кылса.

[...] Керергә теләсәң гыйлем эшенә,
Аяк басма ялган күргән кешеңә.

Белеп үз дошманнарыңны – сугышма,
Кертеп утка салырга да тырышма.

Дөрес гыйлемдә тапса үз эшене,
«Гыйлем иясе!», – дип әйт ул кешене.

Аллаһының шарты да, и тырыш ир,
«Коръән» укуда сабырлык килешер.

# МӘҮЛА КОЛЫЙ

Казан губернасы Лаеш өязе (Татарстанның хәзерге Питрәч районы) Чыты авылында 1630нчы еллар тирәсендә туа. Мамай мелла мәдрәсәсендә укый, аның мөриде. Биләр шәһәре хәрабәләре янына барып урнаша (1678), Петр I фәрманы буенча татарлар ул җирләрдән куылгач, Бөгелмә өязе Иске Иштирәк (Татарстанның хәзерге Лениногорск районы) авылына барып төпләнә.

## Хикмәтләр

Гыйлемлек Хак рәхмәтедер, бел, нур торыр,
Кемне галим кылса Изем, газиз кылыр.
Углан икән, төн-көн гыйлем тәхсил кылыр,
Хак рәхмәте ул колына булыр булгай.

Гыйлемлек Хак рәхмәтедер, бер нур торыр,
Хак кемне газиз кылса, аңа бирер.
Гыйлем белеп, Хак әмре илә, тугры йөрер,
Дөнья-гокбә, морадына йитте булгай.

Гыйлемлек һич кәм булмас, шандыр, белсәң,
Гыйлем белеп, ахирәтлек гамәл кылсаң.
Алып калмас сәндин, гүргә барыр булсаң,
Гүр эчрә, нур у чыраг булыр булгай.

Гыйлемлек күктин инде галимләрә,
Мөрсәл[30], нәби, әүлия тәмамләрә.

[30] Мөрсәл - илче

Газиз кылып, бирде Алла пакь җаннара,
Гыйлем белгән Хак дидарын күрер булгай.

Гыйлемлек күккә охшар, тәхсил кылсаң,
Наданлык дөнья кебек, гакыйл ирсәң,
Хак рәхмәте күкдин инәр, гыйбрәт күрсәң,
Гыйлем әмрен хәлаикъга сачар булгай. (97 б.)

***

Мәгърифәт бостаныны күздин күрсәм, -
Мәгърифәт бостаныны тикмә япмас,
Ихлассызлар, Хактин рәхмәт ләззәт тапмас,
Тәүхиденең дөррәтләре[31] бардыр анда.[...]

Мәгърифәт бостанына күңле ирсә,
Әмре магъруф, нәһи мөнкәр[32] багып күрсә.
Дин исламның хаклыгына күңел бирсә,
Ярлыканмак сыйфатындин бардыр анда.

Хак юлында коллык өчен башын салса,
Хак әмренә газиз җанын корбан чалса,
Бу дөньяны, бер сәгать дип, фани белсә,
Әүлиялык нишаннары[33] бардыр анда.

Мәгърифәт дәрәхтендә[34] һәртөрлек кош,
Ул кошларның чыраглары шәб чирагташ,
Иман эстәр колга булыр гүрдә юлдаш,
Айдан үзгә, төрлек мивә[35] бардыр анда.

Тәүхидең мивәсендин татыса кеше,
Җаны рәхәт табып, булыр күңел хушы;
Гүр өендә Хак катында тәмам эше,
Һәм янә төрлек тирьяк[36] бардыр анда.

[31] Дөррәтләре – энҗеләре
[32] Нәһи мөнкәр – гөнаһ тыю
[33] Нишаннары – билгеләре
[34] дәрәхтендә – агачында
[35] мивә – җимеш
[36] тирьяк – дәва

Тәүхиденең тирьякларын һәркем эчәр,
(Ул адәм ихлас) илә җандин кичәр;
Нәүхә фөрьяд кылып[37], һәркөн яшен сачар,
Андаг колга Хак рәхмәте бардыр анда.

[...] Хак тәүхидне ул колларга бирәседер,–
Җан күзе тәүхид нурын күрәседер
Ул дәрәхтнең мивәләрен тирәседер,
Бостан тулык Хак рәхмәте бардыр анда.

[37] нәүһә фөрьяд кылып – кычкырып зарланып

# ГАБДЕРӘХИМ УТЫЗ ИМӘНИ

Казан губернасы Чистай өязе Утыз Имән (Татарстанның хәзерге Чирмешән районының Яңа Кади) авылында туа (1754). Туган авылының Вилдан мулла мәдрәсәсендә башлангыч белем ала, күрше авылларга барып укый, Оренбург губернасы Каргалы бистәсендә икенче мәчет мәдрәсәсендә белем ала, Бохара, Мәзаре Шаһимәрдән, Акча, Туфи, Сәмәрканд (1788-1796), Бәлх, Һират, Кабул (1796-1798) мәдрәсәләрендә укый һәм укыта. Казан губернасы Чистай өязе Карачишмә (1798 елдан), Исләй, Самара губернасы Бөгелмә өязе Сарабиккол, Куакбаш авылларында укыта, гомеренең соңгы елларын Тимәш авылында үткәрә. 1834 елда вафат була.

## Синең биш асылың

Кеше өчен иң әүвәле – намус, дигән,
Намусыңны сатып, итмә табыш, дигән.
Байлык өчен илен-көнен саткан кеше
Ике дөнья өчен дә ул – явыз, дигән.

Икенче иң кыйммәтлесе – гакыл, дигән,
Гакылсызда тәүфыйк ягы такыр, дигән.
Гакылсызда намус та юк, иман да юк,
Ялганга ант итеп барып сатар, дигән.
Өченче иң кыйммәтлесе – әдәп, дигән,
Әдәп – көчле мәхәббәткә сәбәп, дигән;
Әдәпсездә бәхет тә юк, тәүфыйк та юк,
Кеше исеме күтәрүе гаҗәп, дигән.

Дүртенче иң кыйммәтлесе – күңел, дигән,
Күңеле бозык кеше кеше түгел, дигән,
Бозыкларга җир өстеннән асты яхшы,
Яшәмә дә, үлеп җиргә күмел, дигән.
Бишенче иң кыйммәтлесе – сабыр, дигән,
Сабыр кеше зур бәхетләр табар, дигән,
Бер дә юкка ачуланып дөнья бозу
Бер кайгыдан икенчегә салыр, дигән.

# ЯХЪЯ БИНЕ СӘФӘРГАЛИ (ЯХЪЯ ИШАН)

Казан өязе (Татарстанның хәзерге Әтнә районы) Олы Бәрәзә авылында туа (1758). Каргалы мәдрәсәсендә белем ала. Шекә авылында имам-хатыйб һәм шәех. Шагыйрь һәм табиб. 1838 елда вафат була.

## Васыятьнамә

Хәрдәлидер безә, бәс гыйлем гыйрфан,
Дәхи сыйххәт ула әгъмалү икан.
Замана ичрә галимнәр чугалды,
Фәнүн мөшкиләт һәм шаигъ улды.
Мөдәррисләр гаҗәиб тәдрис идәрләр,
Шәригать гыйлемене тәлбис идәрләр. [...]
Аһәм белмешләр анлар мөшкиләти,
Мәгариф гыйлемедә йук илтифати.
Бу хәл илә кичеп гомер газизе,
Мәгарифтә боларның йук тәмйизе.
Бу мөшкиләти халә калмакта бунлар,
Мәгариф дин кире калмакда бунлар. [...]
Мәгарифтә канәгать әйләмешләр,
Бәлягатьне сәнагать әйләмешләр.
Җәһаләтләрни вә гыйрфан санарлар,
Дәхи шикләрне икан санарлар.
Мәгарифдер гыйлемдәй асыл максуд,

Мәгариф йук, голүм кубдер ничек сад.
Тәм бирүчедер безгә гыйлем, белем,
Сәламәт ясаучыдыр гамәлне анык белү [...]
Галимнәр бу заманда буталып беттеләр,
Фәннең кыенлыгы һәркемгә мәгълүм булды.
Мөдәррисләр гаҗәп рәвештә укытырлар.
Шәригать гыйльман хәйлә һәм алдау итәрләр [...]
Иң әһәмиятлесе, алар авырлыкны белделәр,
Мәгариф гыйльмендә игътибарлары юк.
Шул хәлдә гомерләрен уздырдылар,
Мәгарифтә боларның пакьлеге юк.
Шушы наданлык хәлендә калдылар болар,
Мәгрифтә артта калдылар болар. [...]
Наданлыкны фән санарлар,
Тагын шикле әйберне исбатлаган санарлар. [...]
Имам гыйльмене ачык белмәс,
Аңа дөрес җавапны дәлил тапмый. [...]
Галимлекнең асыл максаты мәгариф,
Мәгарифе юк икән, барлык фәннәр дә
«Сад» хәрефе кебек каты булырлар.

# МӨНӘҖӘТЛӘР

## ЙӘ РӘСҮЛЕМ МӨХӘММӘТ!




1. Йә рәсүлем Мөхәммәт, булды галәмгә рәхмәт!
Чиктең дөнъяда михнәт өммәт өчен, Мөхәммәт.
Аллаһуммә, салли галә Сәйидинә Мөхәммәт!

2. Йә Иляһем, бу галәмне синең өчен яратты,
Әүәленнән ахыр[ы]нача синең ис(е)мең таратты.
Аллаһуммә, салли галә Сәйидинә Мөхәммәт!

3. Мәккә шәһәрендә тудың, атаң иде Абдулла,
Анаң иде Әминә, йә Мостафа Мөхәммәт.
Аллаһуммә, салли галә Сәйидинә Мөхәммәт!

4. Син нәбиләр тәмамы, барчаларның имамы,
Һәр көн сине кадерли Нур, Мостафа Мөхәммәт!
Аллаһуммә, салли галә Сәйидинә Мөхәммәт!

5. Коръән иңдерде сиңа, юлны белдерде сиңа,
Шәригатьне күрсәтте, йә Мостафа Мөхәммәт.
Аллаһуммә, салли галә Сәйидинә Мөхәммәт!

6. Си(й)не Әмин диделәр, си(й)не Кәрим диделәр,
Си(й)не күркәм яхшы диеп, Мәккә халкы мәдехли.
Аллаһуммә, салли галә Сәйидинә Мөхәммәт!

7. Атаң-анаң вафаты си(й)не калдырды ятим,
Алла үстерде си(й)не йә Мостафа Мөхәммәт.
Аллаһуммә, салли галә Сәйидинә Мөхәммәт!

# ДИДЕ МУСА




1. Әй(е), Раббым, – диде Муса, – без(е)гә җәннәт булырмы? – дип.
Сез(е)гә җәннәт булыр(ы), Муса, атаң– анаң риза булса.
Сез(е)гә җәннәт булыр(ы), Муса, атаң– анаң риза булса.

2. Раббем Аллам, – диде Муса, – безгә җәннәт(е) булырмы? – дип.
Сез(е)гә җәннәт булыр(ы), Муса, кылган гамәлләрең булса.
Сез(е)гә җәннәт булыр(ы), Муса, кылган гамәлләрең булса.

3. Әй, Раббем, – диде Муса, – без(е)гә җәннәт(е) булыр(ы) мы? – дип.
Сезгә җәннәт булыр, Муса, чалган корбаннарың булса.
Сез(е)гә җәннәт булыр, Муса, чалган корбаннарың булса.

4. Әй(е), Раббем, – диде Муса, – без(е)гә җәннәт(е) булыр(ы) мы? – дип.
Сезгә җәннәт булыр(ы), Муса, ук(ы)ган намазларың булса.
Сез(е)гә җәннәт булыр(ы), Муса, ук(ы)ган намазларың бул-са.

# ӘЛВИДАГ!




1. Әлвидаг(ы), әлвидаг(ы), хуш килдең, шә[h]ри рәхмәт!
Әлвида[г]!
(Ә)лә Иляhә Иллаллаhе, лә Иляhә Иллалла[h].
Килдегеңдә, йирдә, күктә мәләикләр сөйнешер,
Киттегеңдә, йыглашу бән чуглашырлар. Әлвида[г]!

2. Әлвидаг(ы), әлвидаг(ы), хуш килдең, шә[h]ри рәхмәт!
Әлвида[г]!
Лә Иляhә Иллаллаhе, лә Иляhә Иллалла[h].
Ошбу айда иңде Коръән аять-аять(е) бәйанат,
Хәсәнәтән тәбдил улды җөмлә мәсаәт. Әлвида[г]!

3. Әлвидаг(ы), әлвидаг(ы), хуш кәлдең, шә[h]ри рәхмәт!
Әлвида[г]!
Лә Иляhә Иллаллаhе, лә Иляhә Иллалла[h].
Саф-саф улып мәләикләр йир йөзенә иңәрләр,
Әлләрендин нурдин табак мөэминнәргә сонарлар.
Әлвида[г]!

4. Әлвидаг(ы), әлвидаг(ы), хуш кәлдең, шә[һ]ри рәхмәт!
Әлвида[г]!
Лә Иляһә Иллаллаһе, лә Иляһә Иллалла[һ].
Шатлык белән килдең безгә, сөендердең көндә син,
Дәүләт илән халкы [г]аләм тулды рәхмәт, тулды нур.
Әлвида[г]!

5. Әлвидаг(ы), әлвидаг(ы), хуш кәлдең, шә[һ]ри рәхмәт!
Әлвида[г]!
Лә Иляһә Иллаллаһе, лә Иляһә Иллалла[һ].
Нурың илән зәйн улыптыр җөмлә мәчет(е)ләр тәмам.
Зикре тәс(е)бих(е) вә тәравих киттегеңдә. Әлвида[г]!

6. Әлвидаг(ы), әлвидаг(ы), хуш кәлдең, шә[һ]ри рәхмәт!
Әлвида[г]!
Лә Иляһә Иллаллаһе, лә Иляһә Иллалла[һ].
Хак Тәгалә рәхмәт сачар коллар(ы)га бу айда,
Сайеатдин тыелудан хәсәнәтне кыл(ы)ганга. Әлвида[г]!

7. Әлвидаг(ы), әлвидаг(ы), хуш кәлдең, шә[һ]ри рәхмәт!
Әлвида[г]!
Лә Иляһә Иллаллаһе, лә Иляһә Иллалла[һ].
Фазлың белән сөендердең, хәзер инде китәсең.
Ките бездән рәхмәт ае вә йә хәсрәтә! Әлвида[г]!

8. Әлвидаг(ы), әлвидаг(ы), хуш кәлдең, шә[һ]ри рәхмәт!
Әлвидаг!
Лә Иляһә Иллаллаһе, нуры нәби саллалла[һ].

# ӘЛВИДАГ!




1. «Лә иләһә илләлаһ» ул – гарше көрси сакчысы,
«Лә иләһә илләлаһ» ул – ике җиһан ачкычы.
Әлвидаг, Әлвидаг! Хуш, килдең шәһри Рамазан, Әлвидаг!
Әлвидаг, Әлвидаг! Хуш, килдең шәһри Рамазан, Әлвидаг!

2. «Лә иләһә илләлаһ» ул – изге сүздән изгесе,
«Лә иләһә илләлаһ» ул – ике җиһан көзгесе.
Әлвидаг, Әлвидаг! Хуш, килдең шәһри Рамазан, Әлвидаг!
Әлвидаг, Әлвидаг! Хуш, килдең шәһри Рамазан, Әлвидаг!

3. «Лә иләһә илләлаһ»ны әйтми торма бер заман,
«Лә иләһә илләлаһ»ны әйтәгәннәр бик яман.
Әлвидаг, Әлвидаг! Хуш, килдең шәһри Рамазан, Әлвидаг!
Әлвидаг, Әлвидаг! Хуш, килдең шәһри Рамазан, Әлвидаг!

4. «Лә иләһә илләлаһ»нын карамагыз эзенә,
«Лә иләһә илләлаһ» ул – мәңге бетмәс хәзинә.
Әлвидаг, Әлвидаг! Хуш, килдең шәһри Рамазан, Әлвидаг!
Әлвидаг, Әлвидаг! Хуш, килдең шәһри Рамазан, Әлвидаг!

# МӘРХАБӘ




1. Хак Тәгалә лотыф әйләп, шәһри Рамазан көндерде,
   Шәфкать итеп колларына, рәхмәт аен иңдерде.
   Мәрхәбә(и), мәрхәбә(и), шәһри Рамазан, мәрхәбә!
   Лә Иляһә Иллаллаһе, лә Иляһә Иллалла[h]!
2. Саф-саф улып мәләикләр җир йөзенә иңәрләр,
   Нурдан табак әлләренә мөэминнәргә сонарлар.
   Мәрхәбә(и), мәрхәбә(и), шәһри Рамазан, мәрхәбә!
   Лә Иляһә Иллаллаһе, лә Иляһә Иллалла[h]!
3. Җәһәннәмнең капуларын, бу көн мөхкәм тотарлар,
   Шайтаннарның әлләренә, йөз мең зынҗыр тагарлар.
   Мәрхәбә(и), мәрхәбә(и), шәһри Рамазан, мәрхәбә!
   Лә Иляһә иллаллаһе, лә Иляһә Иллалла[h]!
4. Һәр кичәдә тәүбә кылсаң, лаек улыр җәннәти,
   Аҗаларга ярлы закир, берди булыр нәүмәти.
   Мәрхәбә(и), мәрхәбә(и), шәһри Рамазан, мәрхәбә!
   Лә Иляһә иллаллаһе, лә Иляһә Иллалла[h]!

# ЛӘ ИЛӘҺӘ ИЛЛӘЛЛАҺУ




1. «Лә иләһә илләллаһу» әйтик әле бергәләп,
Рәсүлулла өммәтләре булсак иде бергәләп.

2. «Лә иләһә илләллаһу» әйтик әле бергәләп,
Мәрьям ана туйларында булсак иде бергәләп.

3. «Лә иләһә илләллаһу» иман нурын яктыртыр,
Лә иләһа иллә Аллаһы, хәләл ризык таптырыр.

4. «Лә иләһә илләллаһу» − гарше көрси баскычы,
«Лә иләһә илләллаһу» − сигез оҗмах ачкычы.

5. «Лә иләһә илләллаһ»ның карамагыз әзенә,
«Лә иләһә илләллаһу» − мәңге бетмәс хәзинә.

6. «Лә иләһә илләллаһ»ны әйтми торма берзаман,
«Лә иләһә илләллаһ»ны әйтмәгәннәр бик яман.

7. «Лә иләһә илләллаһу» һәр зекердән хәерле,
«Лә иләһә илләллаһу» мәхшәр өчен әҗерле.

8. «Лә иләһә илләллаһу» − бик кадерле кәлимә.
«Лә иләһә илләллаһу» − урнаштырсын кальбемә.

9. «Лә иләһә илләллаһу» газап эчрэ калдырмас.
«Лә иләһә илләллаһу» җәһәннәмдә яндырмас.

10. «Лә иләһә илләллаһу» сираттан тиз кичерер,
«Лә иләһә илләллаһу» Кәүсәр шәрап эчерер.

11. «Лә иләһә илләллаһу» Хак каршында кадре зур,
«Лә иләһә илләллаһу» шайтан-ләгыйнь булыр хур.

12. «Лә иләһә илләллаһ»ны фирдәвес нуры, дигән,
«Лә иләһә илләллаһу» сәгадәт урыны, дигән.

13. «Лә иләһә илләллаһу» насыйп булсын үлгәндә,
«Лә иләһә илләллаһу» юлдаш булсын күмгәндә.

# КОРБАН МӨНӘҖӘТЕ




1. Хак Тә[г]алә(й) Ибраһим(ы)га шундук әйләди хәрман,
   Мәнем(ы) ризалыгым өчен угылың(ы)ны әйлә кор(ы)бан.

2. Иб(ы)раһим(ы) Хак(ы) сүзен(е) тотты, Исмагыл(е) не(һей) алып китте,
   Диде: «Улым, Алла сине корбан кыйдый хәрман итте».

3. Диде Ис(е)мәгыйл: «И атам(ы), Хак(ы) Тәгаләдер(е) минем әүлям,
   Багла бәнем(е) хур аягым(ы), Хак эм(е)ренәй(е) риза булам».

4. Тур аягым(ы) кысып(ы) багыла, йөземә туры карама,
   Пычагың(ы)ный басып ыш(ы)кы, бер(е) Ходайга(й) асыйм бул(ы)ма.

5. Диде Ис(е)магыйл: «И атам, минем(е) васыятем(е) сиңа,
   Мәмсез өйгә кайта кал(ы)сам, әниемә сәлям әй(е)лә».

6. Минем(е) эчем(е) ег(ы)ламасын(ы), ак сөт әни бәһиллә син.
   Кыямәт кен күрешер(е)без(е), Хак(ы) әмер(е)нәй(е) риза(й) булам.

# МӘҮЛИД




1. Килде аваз күк йөзендә, ишетү бән җир йөзендә:
Дөнъя [а]хирәт сәгадәти – туды бу айда Мостафа!
Дөнъя [а]хирәт сәгадәти – туды бу айда Мостафа!

2. Әминәдер – ил анасы, Халимәдер – сөт анасы,
Абдулладыр – зәд(е) бабасы, туды бу айда Мостафа,
Абдулладыр – зәд(е) бабасы, туды бу айда Мостафа.

3. Бәшәмбе көн(е) таң алдында, Абуталиб ханәсендә
Ятим калды ул анасыз, туды бу айда Мостафа,
Ятим калды ул анасыз, туды бу айда Мостафа.

4. Бабасы булды чиксез шат, Мөхәммәт дип куйдылар ат.
Мәҗлес ясадылар кат-кат – туды бу айда Мостафа.
Мәҗлес ясадылар кат-кат – туды бу айда Мостафа.

5. Туды Мәккә шәһәрендә, Рабигыль-әүвәл аенда,
Бәшәмбе көн уникенче, сәхәр вакты таң алдында,
Бәшәмбе көн уникенче, сәхәр вакты таң алдында.

6. Рәсүлулла туган чакта, төрле хәлләр заһир булды:
Сәва күле суы бетеп, Сәмавадан сулар чыкты.

7. Бәйрәм бу көн(е), бәйрәм бу көн, бик зур шатлык, бәйрәм бу көн,
Кяфер(е) золмәт фылаклары, җиргә ауган көндер бу көн,
Кяфер(е) золмәт фылаклары, җиргә ауган көндер бу көн.

8. Бәйрәм бу көн(е), бәйрәм бу көн, бик зур шатлык, бәйрәм бу көн,
Өч җөз мильон мөселманга шатлык таңы аткан бу көн,
Өч җөз мильон мөселманга шатлык таңы аткан бу көн.

9. Дөнъядагы бар мөселман нигә шатланган бу көн?
Чөнки хәзрәти Мөхәммәт дөнъяга туган бу көн!
Чөнки хәзрәти Мөхәммәт дөнъяга туган бу көн!

# ӘМИНӘ ХАНЫМ – МӨХӘММӘТ АНАСЫ




1. Әминә ханым – Мөхәммәд анасы,
Ул сәдәфтән тугдый энҗү данәсе.

2. Ул Мөхәммәд дөньяга тәшриф итәр,
Вакыт ирештe хәлимәте хәйрел-бәшар.

3. Инде аның калимәсе булды анык,
Күп галәмәт заһир улды алдан ук.

4. Ул рәбигыль-әүвәл аенда иде,
Уникенче кичә − дүшәмбе иде.

5. Гаҗәеп хәл күрде Мөхәммәд анасы,
Күренде нур, нәкъ кояшның яктысы.

6. Ялт итеп чыкты яктылык шул заман,
Күкләрә тик нур белән тулды җиһан.

7. Һәм шунда үзрә түшәлде бер түшәк,
Ады сөндес, түшәгән аны мәләк.

8. Өч әләм калкып чыкты өч җиргә,
Аралары бик ерак бер-беренә.

9. Бере − Мәшрикъ, бере − Мәгърибтә аның,
Бересе − нәкъ уртасында Кәгъбәнең.

10. Мәгълүм булды: ул – Мөбарәкнең нуры,
Заһир булды кәлимәсеннән әүвәле.

11. Иңде күктән күп фәрештәләр саф-саф,
Кәгъбә тирәли кыйлды болар тәваф.

12. Заһир булды дәфгатән өч хур кызы,
Билгесе булмады кайдан кергәне.

13. Өчесе дә янына утырдылар,
«Мостафа туа» диеп, гәп кордылар.

14. Диделәр: «Углың кебек хөрмәтлене
Ул Хода һичбер анага бирмәди.

15. Бик олуг дәүләт иясе буласың,
Холкы күркәм бер угыл тугдырасың.

16. Бу угыл галимнәрнең солтаныдыр,
Бу угыл тәүхид, гыйрфан кянедер».

17. Васфаны болар шуйлә тәртип итте,
Туачак улы белән тәргыйб итте.

18. Диде Әминә: «Вакыт җитте тәмам,
Килә инде дөньяга хәйрел-әнам.

19. Эсселектән сусадым гаятьь каты»,
Шул вакыт эчерделәр бер ширбәти:

20. Ак иде кардан, дәхи салкын иде,
Ул кеби тәм дөньяда һич юк иде.

21. Диде: «Эчтем, барча әгъзам булды нур,
Эчемә һәм тышыма да тулды нур.

22. Килде бер аккош канат белән очып,
Аркамны сыйпады ул монда төшеп».

Тугды ул сәгатьтә ул солтани дин,
Нур гарык булды сәмават-зәмин.

23. Гәр шәфагать лязем улса эзләгез,
Ул Рәсүлнең сөннәтеннән бизмәгез.

24. И Мөхәммәд Мостафа, син и Рәсүл,
Кыйл шәфагать безләрә яумән-нәзүл.

25. Гәр деләрсез уласыз уттан нәҗат -
Гыйшык илә, дәрт илә әйтең ассәләт.

# МӘҖЛЕС МӨНӘҖӘТЕ




1. Безне кунак иттегез сез, тәмле ашларыгыз(ы) белән,
Ходаем сыйласын сез(е)не җомаһ нәүмәтләре белән,
Ходаем сыйласын сез(е)не җомаһ нәүмәтләре белән.

2. Кунак булдык өегездә, дога кылыйык түрегездә,
Җәннәт әҗер(е)ләрен бир(е)сен, бер Ходаем үзегезгә,
Җәннәт әҗер(е)ләрен бир(е)сен, бер Ходаем үзегезгә.

3. Утырмыек фик(е)ре белән, утырыек(и) зик(е)ре белән.
Өстәл тулы ризык белән, без ашыек шөкер белән.
Өстәл тулы ризык белән, без ашыек шөкер белән.

4. Кунак өе җәннәт түре, кунакларың җәннәт хуры.
Кыямәт көн насыйп булсын Рәсүлуллабызның нуры.
Кыямәт көн насыйп булсын Рәсүлуллабызның нуры.

# МӘҖЛЕС МӨБАРӘК БУЛСЫН




1 Мәҗлес мөбарәк булсын, догалар кабул булсын,
Бу мәҗлеснең уртасында Рәсүлуллабыз булсын.

2 Мәҗлес мөбарәк булсын, догалар кабул булсын,
Бу мәҗлеснең уртасында Әминә анабыз булсын.

3 Мәҗлес мөбарәк булсын, догалар кабул булсын,
Бу мәҗлеснең уртасында Гайшә анабыз булсын.

4 Мәҗлес мөбарәк булсын, догалар кабул булсын,
Бу мәҗлеснең уртасында Халим анабыз булсын.

5 Мәҗлес мөбарәк булсын, догалар кабул булсын,
Догаларыбыз кабул булсын, Ходаем риза булсын.

# САБЫРЛЫК МӨНӘҖӘТЕ




1. Атамның(ы) бер(е) гөле идем, анамның(ы) был(ы) былы идем,
Бу хасрәткә гаҗиз(е) бул(ы)дым, сабырлык бир үзең Алла.

2. Сабырлык(ы)ның сынакларын китаплардин караган(ы)нар,
Сабыр ит(е)кән кешеләр(е)не шәһитләр дип санаганнар.

3. И, туганннар, беләсез(е)ме, минем(е) хал(е)нең авыр(ы) лыгын,
Пәйгамбәрләр(е) сабыр ит(е)кән сабыр итеп әҗер ал(ы)ган.

4. Сабыр итик(е), сабыр итик, сабыр коллар(ы) сабыр итә,
Сабыр(ы) коллар сират(ы) күп(е)рен искән җилләр кебек үтә.

5. Сабыр итик(е), сабыр итик, сабыр колдин шайтан(ы) качар,
Сабыр коллар(ы) җәннәт иш(е)ген үз куллары белән ачар.

6. Мөнәҗә(һә)тем сезгә бул(ы)сын, дус(ы)-иш(е)ләрем дога кыл(ы)сын,
Догаларыбыз(ы) кабул(ы) бул(ы)сын, рәхимың(ы) кыл Раббым Алла!

# ВӘЙС ӘЛ-КАРАНИ




1. Һәр сәхәр вакытында калкып гизәр иде,
Япаны-йазаны сәйран идәрде.
Гадәти бу иде, тәвә көтәрде -
Йәмән илләрендә Вәйс әл-Карани,
Гарәп чүлләрендә Вәйс әл-Солтани.

2. Һәр сәхәр вактында бу иде касде,
Ястыгы таш иде, түшәге – пусты.
Алланың Хәбибе, сәүдеге дусты –
Йәмән илләрендә Вәйс әл-Карани,
Гарәп чүлләрендә Вәйс әл-Солтани.

3. Һәр сәхәр вактында бу иде эше:
Арпадан икмәге– йидеге ашы,
Акариде мөбарәк яше –
Йәмән илләрендә Вәйс әл-Карани,
Гарәп чүлләрендә Вәйс әл-Солтани.

4. Кәмәре бар иде аның билендә,
Тәсбихе һәрчак иде әлендә,
Алланың зикере даим телендә –
Йәмән илләрендә Вәйс әл-Карани,
Гарәп чүлләрендә Вәйс әл-Солтани.

5. Гасасы бар иде хөрмә талыннан,
Хиркасы бар иде тәвә йонынннан,
Һич хата чыкмады аның теленнән –
Йәмән илләрендә Вәйс әл-Карани,
Гарәп чүлләрендә Вәйс әл-Солтани.

6. Пәйгамбәр мәсҗедтән өенә керде,
Гайшәдән сорды: «Өйгә кем килде?»
Дустының килдеген нурыннан белде –
Йәмән илләрендә Вәйс әл-Карани,
Гарәп чүлләрендә Вәйс әл-Солтани.

# ДӘРВИШЛӘРНЕҢ СӨХБӘТЕНДӘ




1. Ирәннәрнең мәхфилендә явар рәхмәт сөхбәтендә,
Ни теләсә дә буладыр дәрвишләрнең сөхбәтендә.

2. Әгәр кем сөхбәткә килсә, һәркем аннан өлеш табар,
Әсхабләр морад тапкан дәрвишләрнең сөхбәтендә.

3. Һәркем дә, сөхбәттә булып, куңеленә мәгънә алыр,
Яды килеп, белем булып, дәрвишләрнең сөхбәтендә.

4. Өмме килсә, хас буладыр, йолдыз килсә, ай буладыр,
Бакырдан алтын буладыр дәрвишләрнең сөхбәтендә.

5. Рәсүлемә вәхи килде, башыннан ул таҗын алды,
Шулай ул хадимлек кылды дәрвишләрнең сөхбәтендә.

6. Кол Сөләйман сөхбәтендә, бу дәмбадәм мәнәҗәттә,
Зихи, хасый дәрәҗәттә дәрвишләрнең сөхбәтендә.

# МӘРХАБӘ!




1. Хуш килдегез, мәрхәбә, мәрхәбә, йә мәрхәбә,
Рәхмәт итсен hу Аллаhы, хуш килдегез, мәрхәбә!
Мәрхәбә, йә мәрхәбә,
Рәхмәт итсен hу Аллаhы,
Хуш килдегез, мәрхәбә!

2. Һәр адымыгыз өчен чиксез савап язылсын,
Динебез гафу булынсын, хуш килдегез, мәрхәбә!
Мәрхәбә, йә мәрхәбә,
Рәхмәт итсен hу Аллаhы,
Хуш килдегез, мәрхәбә!

3. Тугры булсын фикрегез, ихлас булсын зикрегез,
Нурды булсын кальбегез, хуш килдегез, мәрхәбә!
Мәрхәбә, йә мәрхәбә,
Рәхмәт итсен hу Аллаhы,
Хуш килдегез, мәрхәбә!

4. Диндә ихлас булыгыз, нияттә саф булыгыз,
Күркәм булыр эшегез, хуш килдегез, мәрхәбә!
Мәрхәбә, йә мәрхәбә,
Рәхмәт итсен hу Аллаhы,
Хуш килдегез, мәрхәбә!

5. Кыямәт көн булганда нурлы булсын йөзегез,
Җәннәт булсын урыныгыз, хуш килдегез, мәрхәбә!
Мәрхәбә, йә мәрхәбә,
Рәхмәт итсен hу Аллаhы,
Хуш килдегез, мәрхәбә!

# ХЫЗЫР ИЛЬЯС




1. Күктән рәхмәт яудырган, җирдә нәбат үстергән,  
Мәхрусатын иңдергән Хызыр Ильяс атам бар.

2. Килеп төзде халканы, эзләп тапмас хал[ы]к аны,  
Тарикаътнең солтаны Хызыр Ильяс атам бар.

3. Килеп халка төзегән, кеме егълап, кем көлгән,  
Кемлеген әүвәл белгән Хызыр Ильяс атам бар.

4. Кем ирдеге билгесез, ару колга әйгүсез,  
Хакдин үзгә билгесез Хызыр Ильяс атам бар.

5. Комда эзен эзләгән, сер сүзләрен сүзләгән,  
Халкдин үзен гизләгән Хызыр Ильяс атам бар.

# КЫЙССАИ ЙОСЫФ




1. Һич берәү дә аны сатып алмады,
Бәһәсенә кем дә аны килалмады,
Мисыр малы аңа бәһа булалмады,
Галәм малы аңы бәһа булмас инде.
2. Хуҗа бикәм, ни сәбәптән күңелең тар,
Йөзең сары, нинди кайгы, борчуың бар?
Җәфаң миннән яшермә син, сөйлә зинһар, –
Хәлең зәгыйфь, кәефең начар булган инде.
3. Зөләйхабыз даясенә җавап бирде,
Даясенә серен ачык әйтеп бирде,
Бу серне ул һәркемнән дә саклык иде,
«Бу серләрне, зинһар, сакла!», – диде инде.
4. Әйтте аңа: Шул Кәнъгәннең кол угланы,
Әйа, дая, беләсеңма икән аны,
Мондый хәлгә тик ул гына мине салды, –
Аның гыйшкы мине шулай кылды инде.
5. Әйе, ханым, гашыйклык ул җиңел булмас,
Табиблар да дәрткә һич тә дәрман белмәс.
Бөтен галәм шат булса да, гашыйк көлмәс,
Сөеклесе кайгысын ул тартыр инде.

# МӨХӘММӘДИЯ




1. Чүн Адәм җәннәтә керди, юча дәүләтләрә йирди,
Каму айләкләре күрди, идерде шөкер лә ихлас.

2. Бакып күрди аны Иблис, хасид кылды идеп,
Аны белмәс иде Адәм, кылырды зөкер (и)лә ихлас.

3. Килеп җәннәт капусында карар итте торып анда,
Күрер к(әе)им чыкты бер тавыс (ш) идерде фәтхәр (и) лә ихлас.

4. Диде ни хуп вә зыя(й)басын әгәр улмыядың һәр(е)гез,
Диде үлмәкендер белдер, кыйлым тафкәр (и)лә ихлас.

# БӘДӘВАМ




1. Иман: Алланы бер белмәк, ислам динен хак белмәк,
   Пәйгамбәрне раст белмәк, «Аллаһ» дигел бәдәвам.
   «Аллаһ» дигел бәдәвам, «Аллаһ» дигел бәдәвам.

2. Белегез Алла берлеген, ислам динен(е) хаклыгын,
   Әхмәд пәйгамбәрлеген, «Аллаһ» дигел бәдәвам.
   «Аллаһ» дигел бәдәвам, «Аллаһ» дигел бәдәвам.

3. Иманны яхшы белең, Хак беорыгын тотың,
   Рәсүл филыген тотың, «Аллаһ» дигел бәдәвам.
   «Аллаһ» дигел бәдәвам, «Аллаһ» дигел бәдәвам.

4. Һәркем белсә иманны, дус тотар Тәңре аны,
   Оҗмахта ахыр урны, «Аллаһ» дигел бәдәвам.
   «Аллаһ» дигел бәдәвам, «Аллаһ» дигел бәдәвам.

5. Иман белгәнне дуст тот, аңа син яхшылык тот,
   Алланың рәхмәтен көт, «Аллаһ» дигел бәдәвам.
   «Аллаһ» дигел бәдәвам, «Аллаһ» дигел бәдәвам.

# АХЫРЗАМАН ЯКИ ТӘКЫЙ ГАҖӘП




1. Йирне нитәк яратдисә күкне һәман,
Айны нитәк яратдисә көнне һәман,
Әнбия-мөрсәлләрне әйтсәм тәмам,
Андин артык тәкый гаҗәп таңнары вар.

2. Замана ахыры булса, ниләр булгай:
Дөньяга төрле-төрле бәла тулгай,
Галимнәре гаҗиз булып, зари кылгай,
Андин артык тәкый гаҗәп таңнары вар.

3. Ир-хатыннар харабатта чагыр эчкәй,
Белер икән, белмәс яңлыш эшләр кылгай,
Дөнья эчрә: «Мәнмен!». – диеп, күксен киргәй,
Андин артык тәкый гаҗәп таңнары вар.

4. Аллаһ диеп, Хак ядына яд кылмагай,
Вәгазь кылган гарифларны ялган дигәй,
Башларына әҗәл уты килмәс сангай,
Андин артык тәкый гаҗәп таңнары бар.

5. Мәсҗед-михраб, мәдрәсәләр коруг калгай,
Пәрһизлек ирәннәрдә һич калмагай,
Залимнәре галимнәргә дад бирмәгәй,
Андин артык тәкый гаҗәп таңнары бар.

6. Салихзадә булганнар да чагыр эчкәй,
Гавам-халык хәрәм эшкә хәрис булгай,
Хак Тәгалә бәла капугын тәмам ачкай,
Андин артык тәкый гаҗәп таңнары вар.

7. Күп ганиләр хәрәм эшкә хәрис булгай,
Күп хатыннар ирләренә хәрәм булгай,
Күп-күп сүзләр сүзләү ул көн бисйар булгай,
Андин артык тәкый гаҗәп таңнары вар.

8. Угыл-кызлар олугларны иза кылгай,
Әдәп-инсаф кылыр йиргә җәфа кылгай,
Ата-ана балаларын зари кылгай,
Андин артык тәкый гаҗәп таңнары вар.

9. Көн-төн дөнья эшен төзеп, фәрван булгай,
Ислам белмәс бәдбәхетләр шадман булгай,
Белгәннәре мескен кеби хәйран булгай,
Андин артык тәкый гаҗәп таңнары вар.

10. Замана ахыры булса, золым тулгай,
Мөэминнәрнең углы-кызы әсир булгай,
Залимнәре офтанмаен «Мәнмен!». − дигәй,
Андин артык тәкый гаҗәп таңнары вар.

# МАНАРА БӘЕТЕ




1. И, манара, ай, урагың каршы иде Кыйблага,
Ничә еллар зекер-тәсбих әйтә идең Аллага.

2. И, манара, ничә еллар сын утырдың нур булып,
Сине кисеп төшергәннәр, йөрсен инде хур булып!

3. И, манара, айларыңны кемнәр килеп кискәннәр?
Бер эчәрлек һәммер өчен үзәгеңне өзгәннәр.

4. И, манара, син утырдың мөэминнәргә билгегә,
Сине кисеп төшергәннәр, хур булсыннар мәңгегә!

5. И, манара, син булмагач, яңгыр яумый күкерәп,
Сине кисеп төшергәндә, җирләр торды тетерәп.

6. И, манара, таң туганда, азан тавышын көтәбез,
Азан тавышын ишетмәгәч, мәхрум булып китәбез.

7. И, манара, синең аең кояш кебек ялтырый,
И, манара син ауганда бар мөселман калтырый.

8. Манара әйтә: «Кисәләр бит, авам-авам, тотыгыз,
Мөселманнар, барчагызда «Вәл-Гасрый»ны укыгыз.

9. И, манара, сине кискәч, барча кошлар таралды,
Азан да юк, намаз да юк, күңелләребез каралды.

10. «Манараны кисәләр», – дип балачага тавышы,
И, манара, син булмагач, бетте азан тавышы.

11. Мәчет әйтә манарага: «Бүген сине кисәләр.
Җилләр бүген Кыйбладан ямансуга бисәләр.

12. Мәчет әйтә: «Юк гөнаһым, сүтәбез дип килгәнсез,
Кыямәт көн минем турыда ничек җавап итәрсез?»

13. Мәчет әйтә: «Мөнбәрләрем һәм бетте михрабларым»
Манара әйтә: «Бәхилләшик, ахыргы минутларым».

14. Манараның тәрәзләре барда җиргә коелды,
Фәрештәләр канат җәеп саф-саф булып җыелды.

15. Биек-биек манараны мөнәфикълар сүтәләр,
Ахыйрәттә мөнәфикълар тәмуг(ы)га китәрләр.

16. Мәчет әйтә халыкларга: «Мине ашыгып сүтмәгез,
Минем турдан узган чакта дога кылмый китмәгез».

# АУДИОЯЗМАЛАРГА КОММЕНТАРИЙЛАР

# КОММЕНТАРИИ К АУДИОЗАПИСЯМ

1. ЙӘ РӘСҮЛЕМ МӨХӘММӘТ. Экспедиционная запись. Записано Г. Макаровым, Л. Сарваровой в июле 2000 г. в с. Кутеевка Белинского р-на Пензенской обл. от М. Д. Дашкиной, 1934 г.р.

2. ДИДЕ МУСА. Экспедиционная запись. Записано Л. Зиганшиной в 2011 г. в д. Татарские Тюки Дрожжановского района Республики Татарстан от Ф.Г. Аббазовой, 1928 г.р.

3. ӘЛВИДАГ. Экспедиционная запись. Записано Г. Макаровым, Л. Сарваровой в июле 2000 г. в с. Кочалейка Каменского р-на Пензенской обл. от Д. А. Янгалычева, 1932 г.р.

4. ӘЛВИДАГ. Исполняет Лилия Зиганшина.

5. МӘРХӘБӘ. Экспедиционная запись. Записано Г. Макаровым, Л. Сарваровой в июле 2000 г. в с. Верхняя Елюзань Городищенского р-на Пензенской обл. от Р. Исляевой, 1939 г.р.

6. ЛӘ ИЛӘҺӘ ИЛЛӘЛЛАҺУ. Исполняет Гульзада Сафиуллина.

7. КОРБАН МӨНӘҖӘТЕ. Экспедиционная запись. Записано Л. Зиганшиной в 2011 г. в с. Малая Цильна Дрожжанов-

ского района Республики Татарстан от Куртляевой Халисы Хасанзяновны, 1939 г.р.

8. МӘҮЛИД. Экспедиционная запись. Записано Г. Макаровым, Л. Сарваровой в июле 2000 г. в с. Верхняя Елюзань Городищенского р-на Пензенской обл. от Р. Исляевой, 1939 г.р.

9. ӘМИНӘ ХАНЫМ – МӨХӘММӘТ АНАСЫ. Исполняет Гульзада Сафиуллина

10. МӘҖЛЕС МӨНӘҖӘТЕ. Экспедиционная запись. Записано Г. Макаровым, Л. Сарваровой в июле 2000 г. в с. Кутеевка Белинского р-на Пензенской обл. от М. Д. Дашкиной, 1934 г.р.

11. МӘҖЛЕС МӨБАРӘК БУЛСЫН. Исполняет Лилия Зиганшина.

12. САБЫРЛЫК МӨНӘҖӘТЕ. Экспедиционная запись. Записано Л. Зиганшиной в 2014 г. в Казани от Курмакаевой Сании Якуповны, 1943 г.р.

13. ВӘЙС ӘЛ-КАРАНИ. Исполняет Гульзада Сафиуллина.

14. ДӘРВИШЛӘРНЕҢ СӨХБӘТЕНДӘ. Исполняет Гульзада Сафиуллина.

15. МӘРХӘБӘ. Исполняет Гульзада Сафиуллина.

16. ХЫЗЫР ИЛЬЯС. Исполняет Гульзада Сафиуллина.

17. КЫЙССАИ ЙОСЫФ. Исполняет Лилия Зиганшина. Записано от С. Аппаковой в г. Казани в 2015 году.

18. МӨХӘММӘДИЯ. Исполняет Лилия Зиганшина.

19. БӘДӘВАМ. Исполняет Гульзада Сафиуллина.

20. АХЫРЗАМАН, яки ТӘКЫЙ ГӘҖӘП. Исполняет Гульзада Сафиуллина.

21. МАНАРА БӘЕТЕ. Исполняет Гульзада Сафиуллина.

# РУХИ МИРАС ӘСӘРЛӘРЕН БАШКАРУЧЫЛАР БӘЙГЕ-ФЕСТИВАЛЕ «ИЛАҺИ МОҢ» КЫСАЛАРЫНДА УЗДЫРЫЛГАН «ТАТАР РУХИ МИРАСЫНДА ГЫЙБАДӘТ ҺӘМ МУЗЫКА» ТҮГӘРӘК ӨСТӘЛ РЕЗОЛЮЦИЯСЕ

**2022 ел, 14 апрель Россия ислам институты**

«Татар рухи мирасында гыйбадәт һәм музыка» дип аталган түгәрәк өстәл 2022 елда чираттагы Төбәкара рухи мирас әсәрләрен башкаручылар бәйге-фестивале «Илаһи моң» кысаларында Россия ислам институтында уздырылды.

2014нче елдан башлап агымдагы елда алтынчы тапкыр уздырылган «Илаһи моң» бәйге-фестивале Россия ислам институты башлангычында, Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы каршындагы Республика традицион мәдәниятне үстерү үзәге, Бөтендөнья татар конгрессы, Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте, Казан федераль университетының Халыкара мөнәсәбәтләр институты, Болгар ислам академиясе, Татарстан фәннәр академиясенең Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, «Гөлзадә» иҗат студиясе ярдәмендә уздырылып килә.

Быел бу чара Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулуга багышлана.

«Илаһи моң» бәйге-фестиваленең максатлары: татар халкының рухи традицияләрен үстерү һәм пропагандалау, җәмгыятьтә милләтара мөнәсәбәтләр һәм татулык булдыру, Идел-Урал төбәге халыклары арасында рухи мирасыбыз ядкарьләрен (мөнәҗәт, бәет, көйләп китап уку, татар мәкаме белән Коръән уку) көйләп башкару традицияләрен популярлаштыру һәм саклау. Конкурс программасына халык авыз иҗаты әсәрләрен башкару (мөнәҗәтләр, бәетләр, эпос-дастаннар, зикерләр), әдәби мирас үрнәкләрен башкару («Кыйссаи Йосыф», «Бәдавам», «Кисек-баш» һ. б.), татар мәкаме традицияләрендә Коръән уку керә.

Алдагы елларда «Илаһи моң» фестиваль-бәйгесе кысаларында педагогларга һәм иҗат коллективларының җитәкчеләре өчен, дистанцион белем бирү технологияләрен һәм электрон ресурсларны кулланып, «Рухи мәдәният әсәрләрен башкару аша тарихи мирасны сәнгати-эстетик яктан кабул итүне тәрбияләү» курслары үткәрелде. Курс барышында галимнәр, дин, сәнгать әһелләре тарафыннан лекцияләр укылды, бу өлкәдә булган алдынгы тикшеренүчеләр, рухи мирасыбыз әсәрләрен башкаручылар тарафыннан мастер-класслар уздырылды. Рухи мәдәният традицияләрен, халык авыз иҗаты һәм язма мирас әсәрләрен, татар мәкаме белән Коръән уку традицияләрен саклау, өйрәнү һәм тергезү белән бәйле сораулар буенча фикер алышулар үткәрелде. Тест рәвешендә әзерләнгән сынауны тапшыручыларга, уку нәтиҗәләре нигезендә, квалификация күтәрү турында таныклык бирелде.

Быелгы конкурсның нәтиҗәләре хакында, халык авыз иҗаты әсәрләрен саклау, өйрәнү һәм яңадан торгызу, башкару традицияләре белән бәйле мәсьәләләр буенча фикер алышу нияте белән 2022 елның 14нче апрелендә «Татар рухи мәдәниятендә гыйбадәт һәм музыка» дип аталган түгәрәк өстәл уздырылды. Чарада жюри әгъзалары, педагоглар, иҗат

коллективлары җитәкчеләре, галимнәр һәм танылган рухи мирас әсәрләрен башкаручылар катнашты. Чара кысаларында Казан дәүләт консерваториясенең татар музыкасы һәм этномузыкология кафедрасы доценты, юбиляр Геннадий Михаил улы Макаровның ачык дәресе узды. Шулай ук Россиянең төрле төбәкләрендәге катнашучылар белән онлайн трансляция оештырылды.

Түгәрәк өстәл барышында түбәндәге фикерләр тәкъдим ителде.

Рухи мирасыбыз ядкарьләре (мөнәҗәт, бәет, көйләп китап уку, татар мәкаме белән Коръән уку) – мирасыбызның аерылгысыз өлеше. Бу максатка ирешү өчен түбәндәге гамәлләрне үтәү шарт:

1. Татарстан Республикасының мәдәният министрлыгы каршындагы мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәгенә (Казан дәүләт консерваториясе белән берлектә):

- көйләп уку сәнгате буенча иҗат җитәкчеләре, остазлар әзерләү буенча төбәкара курслар оештырырга;

- көйләп уку буенча укыту әсбаблары, методик ярдәмлекләр булдырырга;

- уен коралларын җитештерү буенча остаханә оештыруны алгы планга куярга;

- аудио, видео язмалар әзерләп, регионнарга, фольклор коллективларына җиткерергә.

2. Татарстан Республикасының уку-укыту, мәдәният оешмаларына (Казан дәүләт консерваториясе, Казан дәүләт мәдәният институты, Казан музыка көллияте, Педагогика көллиятләре, музыка мәктәпләре, гомум белем бирү мәктәпләре, мәдәният йортлары һ.б.):

- көйләп уку сәнгатенә игътибарны арттырырга;

- фольклор ансамбльләре оештырырга;

- мастер класс, ачык дәресләр оештырырга.

3. Татарстан фәннәр академиясенә, Г.Ибраһимов исемендәге Тел әдәбият, сәнгать институтына, Шиһабетдин Мәрҗани исемендәге тарих институтына:

- халык авыз иҗатының беренчел фольклор башкаручыларның үрнәкләрен туплап, аудио, видео язмаларын институт сайтына урнаштырырга;

- татар халкының рухи мирасы әсәрләрен көйләп уку юнәлешен фәнни яктан өйрәнүгә багышланган чаралар (конференцияләр, түгәрәк өстәлләр) оештырырга, фәнни мәкаләләр җыентыклары, фәнни хезмәтләр булдырырга;

4. Татарстан Диния нәзарәте ярдәменә без мохтаҗ, чөнки бәет-мөнәҗәт көйләп уку традициясен элек-электән халыкка таратуда шәкертләр зур роль уйнаганын исәпкә алып:

- татар мәкамен саклау, популярлаштыру өчен татар мәкаме белән Коръән уку бәйгеләре уздырырга;

- мәдрәсәләр, дини уку йортлары уку-укыту программаларына татар халкының рухи мирасы үрнәкләрен чагылдырган дәресләр кертергә;

- мәдрәсә шәкертләрен, мәчет каршындагы курсларда укучыларны татар халкының рухи мирасы үрнәкләре белән таныштырып, әхлак тәрбиясе өлкәсендә халкыбыз мирасына мәхәббәт тәрбияләүче чаралар оештырырга.

5. Болгар ислам академиясенә:

- татар халкының рухи мирасы әсәрләрен көйләп уку юнәлешен фәнни яктан өйрәнүгә багышланган чаралар (конференцияләр, түгәрәк өстәлләр) оештырырга, фәнни хезмәтләр булдырырга;

- Болгар ислам академиясе уку-укыту программасына татар халкының рухи мирасы үрнәкләрен чагылдырган дәресләр кертергә;

- Болгар ислам академисе шәкертләрен татар халкының рухи мирасы үрнәкләре белән таныштырып, әхлак тәрбиясе өлкәсендә халкыбыз мирасына мәхәббәт тәрбияләүче чаралар оештырырга.

6. Бөтендөнья татар конгрессына:

- татар халкының рухи мирасыбыз ядкарьләрен башкару (мөнәҗәт, бәет, дастан, зикер, көйләп китап уку, татар мәкаме белән Коръән уку) традицияләрен популярлаштыру нияте белән көйләп уку буенча укыту әсбаблары, методик ярдәмлекләре, халык авыз иҗаты үрнәкләренең аудио, видео язмаларын тиражлап бөтен дөнья татарларына тарату;

- татар халкының рухи мирасына багышланган чаралар (конференцияләр, түгәрәк өстәлләр) оештырырга, җыентыклар булдырырга.

7. Телевидение, радио, массакүләм чараларына:

- татар халкының рухи мирасыбыз ядкарьләрен башкару (мөнәҗәт, бәет, дастан, зикер, көйләп китап уку, татар мәкаме белән Коръән уку) традицияләрен популярлаштыру өчен тапшырулар әзерләргә.

- бүгенге көндә рухи мирасыбыз ядкарьләренә ихтыяҗ зурлыгын искә алып, дини бәйрәмнәрдән тыш ошбу әсәрләрне ешрак яңгыратырга.

8. Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү комиссиясенә:

- рухи мирасыбыз, халык аваз иҗаты әсәрләрендә туган телебезнең нигезе. Шуны исәпкә алып бу мирасны саклау, барлау, киләчәк буыннарга тапшыру максаты белән бу юнәлешкә игътибарны юнәлтергә, грантлар булдырырга.

9. Татар халкының сәнгать әһелләренә:

- без – үткән белән киләчәкне тоташтыручы күпернең баганалары. Әлегә сез һәм без бар, киләчәк буын башкачарак. Бармак белән генә санарлык милли җанлы яшьләребезгә без тамырдан дөрес мәгълүмат җиткереп калдырырга тиеш. Шул исәптән, үз репертуарларыгызда рухи мирасыбыз әсәрләренә игътибарны юнәлдереп, аларны иман бөркеп торган, күңелдән әйтелүенә һәм дөрес башкару осталыгына ирешеп халыкка җиткерүегезне үтенәбез.

- мөнәҗәт-бәетләрнең потенциалы биниһая зур. Аны халыклашкан формада гына саклап калдыру белән генә чикләнмичә, заманча башкару ысулларын эзләү һәм үстерү кирәктер.

Түгәрәк өстәлнең Ислам институтында узуында олы мәгънә бар. Татар мөнәҗәтен үстереп, дөнья күләменә күтәрергә, милли традицияләрдә башкаручы профессионалларны үстерергә кирәк. Бу мирасны саклау, барлау, киләчәк буыннарга тапшыру безнең изге максатыбыз!

*«Татар рухи мирасында гыйбадәт һәм музыка» түгәрәк өстәлендә катнашучылар.*

*14.04.2022. Казан. Россия ислам институты.*